

КОМГА ТЕРӘЛҮ

Иделдә су кимү илкүләм проблемага әйләнде

> 5

УТЫН КАЙГЫСЫ

Нурлат районының 36 йортлы Каракүл авылында яшәүчеләр газ көтә

> 15



РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН:

«Шәхси саулык – бер хәл, милләткә саулык сорыйм»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 173 (29140) | Җомга | 24 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КУЕНЫ – ГӨЛБАКЧА

ҖИРГӘ – МАТУРЛЫК, ИЛГӘ БАТЫРЛЫК БИРҮЧЕЛӘР ТУРЫНДА БАЛАЛАРЫ СӨЙЛИ

Аларга карата булган яратуны күрсәтмибез, нигәдер матур сүзләргә дә саранрак без. Югыйсә йөрәкнең түр почмагында йөрткән мәхәббәтне, наз һәм җылыны кызганмыйсы, кадерләрен беләсе иде. Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә генә түгел, һәр көнне. Язмабыз геройлары да кат-кат кабатлады бу фикерне, әниле чакның кадере һәм рәхәте турында да әйтте.

> 17

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путин 2024 елны Гаилә елы дип игълан итте. Указда әйтелгәнчә, бу карар гаилә һәм традицион кыйммәтләрне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен халыкка күбрәк таныту өчен кабул ителгән.

Хөкүмәт 27 декабрьгә кадәр оештыру комитеты булдырачак. Шулай ук Гаилә елы уңаеннан уздырылачак төп чаралар планы эшләп расланачак, чаралар өчен акча чыганаклары билгеләнәчәк.

Билгеле булганча, киләсе ел Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы буларак та игълан ителде.

Татарстанда барлыгы 170,4 мең кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты исәпләнә. Татарстан икътисад министрының беренче урынбасары – Эшмәкәрлекне үстерү департаменты директоры Наталья Кондратова әйтүенчә, ел башына аларның саны 5,5 меңгә арткан. Әлеге өлкәдә барлыгы 827,3 мең кеше хезмәт куя. Эшләүчеләрнең гомуми санының 40 проценты чамасы бу. Бүген республикада кече һәм урта бизнесны үстерү өчен барлык шартлар тудырыла. Алар икътисадка зур өлеш кертә, яңа эш урыннары булдыра. Наталья Кондратова әйтүенчә, эшмәкәрләргә, бизнесны үстерү өчен, федераль һәм республика чараларыннан мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга кирәк.

Әниләр көне алдыннан Россия Социаль фондының Татарстан бүлегендә ана капиталына 400 меңенче сертификат рәсмиләштерделәр. Юбилей сертификатының бәхетле хуҗалары – Казаннан Фәйзуллиннар гаиләсе. Кызлары Айдана – Әдилә һәм Айдар Фәйзуллиннарның көтеп алынган беренче баласы. Билгеле булганча, 2020 елның апреленнән дәүләт сертификатлары Дәүләт хезмәтләре порталында (gosuslugi.ru) әнинең шәхси кабинетына керүче электрон документ рәвешендә формалаша. Республикада Татарстан Социаль фондына мөрәҗәгать итмичә, шул рәвешле 95 меңнән артык сертификат рәсмиләштерелгән.

Январьларда республикада һава температурасының 0 градустан югары булуы күзәтелә. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 25 ноябрьдә шактый ук җылыта. Көндез һава температурасы –3…+1, төнлә –4…–12 градус чикләрендә тирбәләчәк. Юеш кар-яңгыр, кайбер районнарда буран, томан һәм юлларда бозлавык булачак.

Якшәмбе – 26 ноябрьдә көндез җылы: 0…+2 градус. Төнлә термометрның терекөмеш баганасы –2…–7 градус күрсәтәчәк. Бозлавык. Дүшәмбе – 27 ноябрьдә республикада төнлә яңгырлар явып үтәчәк. Көндез явым-төшем көтелми. Һава температурасы көндез 0…+3, төнлә 0…–3 градус тәшкил итәчәк. Сишәмбе – 28 ноябрьдә явым-төшем көтелми. Көндез 0…–3, төнлә –1…–6 градус.

Районнарда ни хәлләр?

Апас

Район үзәгендәге бер урамга Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев исемен бирәчәкләр. Бу хакта Апаста танылган әдипнең 95 еллыгы уңаеннан узган искә алу чарасында әйттеләр. Хәзерге вакытта Олы Бакырчы мәктәбе Шәүкәт Галиев исемен йөртә, туган авылында музей-йорты бар. Якташлары шагыйрьне быел да зурлап искә алды. Район үзәк китапханәсе янындагы бюстка чәчәкләр салдылар, музей, мәдәният йорты хезмәткәрләре, заманында аның белән аралышып яшәгән кешеләр хатирәләре белән уртаклашты.
(«Апас-информ»)

Саба

Шәмәрдәндә яшәүче Тайфә әби Лотфуллина 103 яшен тутырды. Дөнья мәшәкатьләрен күреп, ачлык-ялангачлыкны үз җилкәсендә татып, сугыш афәтләрен кичереп, парлы тормыш коргач, 8 бала тәрбияләп үстергән Тайфә әбине тәбрикләргә район башлыгы Рәис Миңнеханов килде. Район башлыгы Тайфә әбигә сәламәтлек, бәхетле картлык теләде. Алар үткәннәр турында озак сөйләшеп утырдылар. «8 бала тәрбияләп үстердек, оныкларым инде 50 яшьтән уздылар, 20 оныкчыгым бар. Күп бала тапсагыз, гомерегез озын булыр», – ди ул.
(«Саба ТВ»)

Балтач

Балтач гимназиясендә, Украинада махсус хәрби операциядә катнашып, хәрби хезмәт бурычын үтәгәндә һәлак булган Рөстәм Фәйзрахманов исеме мәңгеләштерелде. Ватан алдындагы бурычын үтәгәндә батырларча һәлак булган разведка ротасының гвардия кече сержанты 2009–2020 елларда Балтач гимназиясендә белем ала. Һава-десант гаскәрләрендә хәрби хезмәтен тәмамлагач, контракт төзи. Махсус хәрби операциянең беренче көннәреннән үк алгы сызыкта була, ике тапкыр яралана. Рөстәм Фәйзрахмановны апрель аенда Балтач бистәсе зиратында җирләделәр.
(«Хезмәт»)

Актаныш

Киров авылында яшәүче күпбалалы ана Венера Сабитова шушы көннәрдә Мәскәүгә, академик Бурденко исемендәге баш хәрби клиник госпитальгә барып кайтты. Авылдашы, махсус хәрби операциядә каты яраланып, контузия алган Альберт Җиһангировның хәлен белде ул. Туган як җылысын алып килгән апасын күргәч, нәкъ Актаныште гына пешерелә торган чәкчәкне, хуш исле ипекәйне авыз иткәч, егет икеләтә көч кереп киткән кебек сизә үзен. Альберт авылдашлары, райондашлары җибәргән күчтәнәчләр белән палатада бергә яткан дусларын сыйлый.
(«Актаныш»)

ТЕЛДӘН БАШЛАНА

Кытлыксыз бюджет, чит телдән кергән сүзләрдән котылу теләге һәм болай да аңлашыла торган ватанпәрвәрлек. Татарстан Дәүләт Советының чираттагы утырышында депутатлар әнә шул хакта сөйләште.

Башкалада алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы узды. Төп вакыйга: депутатлар 2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына бюджет проектын икенче һәм өченче укылышта кабул итте.

– Документка бәйле 200 төзәтмә керде. Шул исәптән, КПРФ депутатларыннан килгән һәм бюджетны тагын да «авырайтучы» 17 төзәтмә дә бар иде. Фикер алышу барышында алар авторлары тарафыннан караудан алынды, – диде парламентның Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты җитәкчесе Леонид Якунин.

Депутат сүзләренә караганда, төзәтмәләр нигезендә, киләсе елга федераль бюджеттан финанслау 15,7 миллиардка артып, 67,4 миллиард сумга җиткән. Өстәмә акча сәламәтлек саклау, юл хуҗалыгы, мәгариф, авыл хуҗалыгы кебек тармакларга тотылачак, диделәр утырышта. Киләсе ел бюджеты кытлыксыз булачак дип көтелә. Керемнәр һәм чыгымнар 399,5 миллиард сум күләмендә билгеләнгән. Закон проекты документын якын арада ук, имзалау өчен, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка тапшырачаклар.

– Без җентекле һәм җитди эш башкардык, – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика Хөкүмәте белән берлектә башкарган эшкә йомгак ясап.

Татарстан депутатлары Дәүләт Думасына «Россия Федерациясенең дәүләт теле турында»гы Законга үзгәрешләр кертү турындагы закон проектының эчтәлеген тәгаенләштерү тәкъдиме белән дә чыкты. Әлеге документ халык телендә «англицизмнар турындагы закон» буларак билгеле. Ул инглиз һәм башка чит телләрдән алынган сүзләрне куллануны чикләүне күз уңында тота. Мәсәлән, җәмәгать урыннарында чит телдә язылган кибет исемнәреннән, «Sale», «Coffee» кебек адым саен диярлек очрый торган язулардан баш тартырга, аларны Россия дәүләт телендә язарга тәкъдим итәләр.

Мәгънәсе бар. Әмма закон проекты текстында милли республикалар мәнфәгатьләре исәпкә алынмаган, диделәр утырышта. Фәлән шәһәрдә салынучы торак комплексына исем биргәндә, мәсәлән, рус теле белән беррәттән, милли халыкларның туган телләрен файдалану мөмкинлеген дә акка кара белән язарга кирәклеген әйттеләр. Федераль дәрәҗәдә бу мәсьәләне контрольдә тотуны Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәрраховка йөкләделәр.

Утырышта «Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү турында»гы закон проектын икенче укылышта һәм тулысынча кабул иттеләр.

Билгеле булганча, әлеге закон проекты моңа кадәр узган утырышта да, комитетта сөйләшүләр барышында да шактый фикерләр уяткан иде. Депутатлар документта «патриотизм» төшенчәсенә тәгаен аңлатма бирелмәвен әйтте.

Икенче укылышта исә эшне бик тиз тоттылар.

– «Ватан», «патриотизм» кебек төшенчәләр гомуми кабул ителгән. Аларга өстәмә рәвештә аңлатма бирергә кирәкми, – диде парламентның Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов.

Бу юлы фикер әйтүче булмады.

– Закон проектын укыдыгызмы? – дип тә сорап куйды Фәрит Мөхәммәтшин залда утыручылардан. Фикерен дәвам иттереп: «Бүген патриотик тәрбия мәсьәләсе көн кадагында тора. Ул әлеге юнәлештә эшләүче барлык министрлыклар һәм башкарма хакимият органнары эшенә кагыла. Ватанпәрвәрлек тәрбияләү, яшь буынга әлеге кыйммәтләрне тапшыру – мөһим бурыч», – дип тә өстәде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

tatarstan.ru

Татарстан Дәүләт Советында «Язылу бүләк ит!» хәйрия акциясе узды. Парламент утырышында катнашкан депутатлар 2024 елның беренче яртыеллыгына газета-журналларга язылды. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин гадәттәгечә Баулы картлар йортында яшәүче әби-бабайлар өчен дип «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталары, «Сөембикә» журналына язылды. «Өлкәннәр ил-көн яңалыклары белән танышып барсын, дөнья хәлләрен белеп торсын», – диде ул.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Әлмәт муниципаль районы буенча Бишмунча авылыннан биш бала анасы **Галиәкбәрова** Дилбәр Юныс кызы, Әлмәт шәһәреннән биш бала анасы **Мәхмүдова** Мәдинә Габдессәлам кызы, Бөгелмә муниципаль районы буенча Бөгелмә шәһәреннән биш бала анасы **Шәйгәрдәнова** Руфина Рәшит кызы, Зеленодольск муниципаль районы буенча Октябрь поселогыннан алты бала анасы (аларның бишесе өч яшькә җиткән) **Трофимова** Камилә Бәдгетдин кызы, Питрәч муниципаль районы буенча Көек авылыннан биш бала анасы **Хөснуллина** Гүзәл Шамил кызы, Азнакай муниципаль районы буенча Актүбә шәһәр тибындагы поселогыннан биш бала анасы **Кәримова** Эльвира Өлфәт кызы, Әлмәт муниципаль районы буенча Әлмәт шәһәреннән биш бала анасы **Яббарова** София Зөфәр кызы Татарстан Республикасының **«Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең оториноларингология бүлекчәсе табиб-оториноларингологы **Газизова** Алсу Әнвәр кызына, «Апас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы **Гайнуллина** Гөлсинә Хәлим кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең яңа туган балалар өчен реанимация һәм интенсив терапия бүлекчәсе табибы – анестезиологы-реаниматологы **Мостюкова** Гөлназ Хәйдәр кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең пешеп җәрәхәтләнү бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Новиков** Радик Ганс улына, «Минзәлә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең анестезиология һәм реанимация бүлекчәсе мөдире – табибы – анестезиологы-реаниматологы **Хәйруллин** Рафаел Нәркиз улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең урология бүлекчәсе табибы – балалар хирургы **Чебышев** Александр Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Әлмәтнең ашыгыч медицина ярдәме станциясе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Әгъзамов** Фәйзи Фирдәүс улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕСПУБЛИКА КАЙГЫРТА

Һәр мөрәҗәгать исәптә. Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүче оешма, хәрәкәт вәкилләре шулай дип ышандыра.

«Ярдәм янәшә!» республика хәрәкәте җитәкчесе Ринат Фазыйлов сүзләренә караганда, волонтерлар егетләргә генә түгел, аларның гаиләләренә дә ярдәм итә. Араларында шундук хәл итәрлекләре дә, шактый катлаулылары да бар.

– Мондый мөрәҗәгатьләрне кабул итү өчен махсус «кайнар элемтә» эшли. Аларның күбесен район-шәһәрләргә юллыйбыз. Ник дигәндә, алар адреслы ярдәм, көнкүреш мәшәкатьләре, социаль ярдәм чараларына бәйле. Кемгәдер утын ярып бирергә, кемнеңдер машина тәгәрмәчен алмаштырырга кирәк. Егетләр үзләре күбрәк нинди сорау буенча кая барырга кирәклеге белән кызыксына. Эшне җиңеләйтү өчен баштан ук социаль портретлар булдырдык, – ди Ринат Фазыйлов.

Социаль портрет дигәндә, махсус хәрби операциядә катнашучының яше, белеме, социаль хәле, укыган, яшәгән урыны, гаиләсе турында тулы мәгълүмат тупланган җыентык күздә тотыла. Ринат Фазыйлов сүзләренә караганда, анда язылганнар егетләрнең гаиләләренә ярдәм итүне җиңеләйтә.

Билгеле булганча, күптән түгел Татарстанда «Үзебезнекеләрне кайгыртып» дип исемләнгән программа нигезендә махсус сайт (zabotasvo.tatar) һәм «Телеграм»да махсус чат-бот эшли башлады. Бирелә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә тиешле барлык ярдәм чаралары турында тулы мәгълүмат тупланган. Шунда ук борчыган сорауларны да җиткерергә мөмкин.

Бу эшкә иҗтимагый оешма, хәрәкәт вәкилләре дә зур өлеш кертә. Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева сүзләренә караганда, бүген Кукмара һәм Спас районнарында махсус хәрби операциядә катнашкан егетләргә һәм аларның гаиләләренә бушлай тернәкләнергә ярдәм иткән оешмалар бар.

– Махсус хәрби операциядән кайткан егетләребез дә тик утырмыйк – элеккеге эшенә кайта яки яңа һөнәр үзләштерә. Без аларга ярдәм итәбез. Мисал өчен Азнакайдан Рөстәм Мотыйгуллин белән Марат Аббасовны гына алыйк. Азнакай районының Чәкән авылы егете Рөстәм үз теләге белән махсус хәрби операциядә булып кайткач, 10 сыер алып, фермерлык эшенә кереште. Марат исә МХОдан кайткач, умартачылык белән шөгыльләнә башлады. Бүген ул бергә хезмәт иткән егетләргә бал җибәреп тора, – дип сөйләде Зилә Вәлиева.

Балалар аеруча игътибар үзәгендә. Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Сабирова сүзләренә караганда, бүген министрлык базасында урнашкан барлык белем бирү үзәкләрендә әтиләре махсус хәрби операциядә катнашкан балаларга психологик ярдәм күрсәтелә.

– Без аларга барлык борчу, куркуларын җиңәргә ярдәм итәбез. Профессионал психологлар, махсус медицина үзәкләре белән эшлибез, – ди ул.

Министрлык бу максаттан махсус «ышаныч телефоны» да булдырган. Бирегә бер меңнән артык шалтырату килеп ирешкән инде. Психологик ярдәмгә мохтаҗ һәркем **8 800 200 01 22, 8 800 555 22 20** номерлары буенча шалтырата ала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

НЕЧКӘ КҮҢЕЛЛЕ СӘЯСӘТЧЕ

«Халкына хезмәт итеп, матур тормыш алып барды». Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин күп еллар бергә эшләгән чордашы Роберт Миңнуллинны әнә шундый сүзләр белән искә алды. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә шагыйрьнең 75 еллыгына багышланган кичә узды.

– Республикага бөтен көчен, гомерен биргән якын кешебез – Роберт Миңнуллинны онытмыйбыз, истә тотабыз. Туган телебезне безгә өйрәтүче, саклап калучы, алга алып баручы егетләребезнең берсе. Без аның белән бик дус эшләдек. Ничә еллар депутат булды бит, минем урынбасарым булып та эшләде. Халык белән иң авыр очрашуларга да Роберт бара иде. Аның әйткән сүзләре һаман истә: гомер үтми ул, ә без аннан үтәбез. Бу, чыннан да, шулай. Роберт та үз юлын намус белән үтеп, якты дөньядан китеп барды, – дип сөйләде парламент җитәкчесе. – Вакыт узу белән Робертның юклыгы тагын да ныграк сизелә, сагындыра. Аның чыгышлары хәзер дә истә. Иплe, мөлаем, олы йөрәкле, кычкырып та әйтмәс. Сөйкемле кеше иде бит Роберт. Матур гына чыгып, үзенең фикерен туплап, әйтәсе сүзен җиткерә иде. Еш кына үзен нечкә күңелле сәясәтче дип атый иде. «Без бит – язучылар, шагыйрьләр – тормышка, дөньяга икенче төрләрәк карыйбыз», – ди иде. Безне дә шуңа өйрәтә иде. Йөрәге янды, ләкин үз-үзен тыеп, моны күрсәтмәскә тырышты. Аңа гына хас булган юмор хисе, күңел зирәклегенә соклана идек. Елмаеп та әйтә иде, сүккән чакта, тәнкыйтьләсә дә, ачу калмый иде аңа. «Бәхетле кеше шагыйрь була алмый», – дип әйтә торган иде Роберт. Мин моның белән килешеп бетмәдем. «Ватанга, үз халкына шуның кадәр файда китергәндә, сине шулай яратканда һәм кадерләгәндә бәхетсез була алмыйсың», – дидем. Халкына хезмәт итеп, матур тормыш алып барды. Роберт Миңнуллинның иҗат чаткысы һәм игелекле гамәлләре безнең күңелләрдә, аның укучылары һәм киләчәкләре өчен көрәшкән халкыбызның хәтерендә мәңге сакланыр.

Кичәдә Роберт Миңнуллин исемендәге иң яхшы балалар әсәрләренә республика әдәби конкурсында җиңүчеләрне дә бүләкләделәр.

Ләйсән САФИНА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Җитешсезлек

Иратабыз бүтәннәрнең җитешсезлеген күрергә. Нәрсәгәдер сәләте булып, ниндидер уңышка ирешкәннәрнекен – бигрәк тә. Андыйларның җитешсезлеге безнең өстенлек кебек тоела, абруебызны күтәреп җибәргәндәй була. Шуңа да алар турында сүз чыкса, горурланып, хәтта беразмактанып сөйлибез.

Бар яктан да камил кеше булмый. Булырга тиеш тә түгел. Кирәкми дә…

Күз алдына китереп карагыз менә, сез – бөтен яхшы сыйфатларны җыйган идеаль кеше, ди: матур да, батыр да, сәламәт тә, бай да, талантлы да… Бөтен әйбәт сыйфатларыгыз бар, бөтен нәрсәгә житеш, бернигә дә мохтаҗлыгыгыз юк… Димәк сезгә бернәрсә дә кирәкми. Беркем дә. Һәм бөтен тирә-як сезнең кебек үк камил затлардан тора.

Бу очракта тормышның максаты югала: сез беркемгә дә кирәкмисез, сезгә беркем дә кирәкми – нәрсә хакына яшәргә?

Ярый, бер сез генә – дөньяның иң камил заты, ди. Бүтәннәр андый түгел. Шуннан? Нәрсә эшлисез инде? Әлбәттә, ниндидер изге гамәлләр кылырга, мохтаҗларга ярдәм итәргә мөмкин. Ачка – икмәк, йортсызга – йорт, акчасызга – акча. Тик монда да сез чикләнгән. Сез ямьсез кешегә – матурлык, куркакка – батырлык, көчсезгә көч бүлеп бирә алмыйсыз.

Без гомер буена тирә-ягыбыздагыларга акыл бирергә тырышабыз, шулай итсәк, бөтен кеше дә безнең кебек акыллы булыр, дип уйлыйбыз. Тик берни килеп чыкмый, чөнки без биргән акылны бирәү дә алырга теләми, һәркем үз акылы белән яшәргә тели. Бар мәсьәләдә дә шулай: ямьсезләр үз матурлыгы белән яши, куркаклар үз батырлыгы белән.

Сез дөньяда бердәнбер камил зат булсагыз да, аннан беркемгә дә әллә ни файда юк. Чөнки камиллек дәрәҗәсен һәркем үз мөмкинлегеннән бәяли: ямьсезләр – үз ямьсезлеге, куркаклар үз куркаклыгы аша. Ахмакларга үз ахмаклыгы ахмаклык булып түгел, ә табигый халәт булып күренә. Димәк, камиллек дәрәҗәсен билгеләүдә бердәй планка була алмый. Һәм бернинди җитешсезлек тә булмаган җирдә камиллекнең дә мәгънәсе югала. Асылда, камиллек ул – бернигә дә кирәкми торган файдасыз дәрәҗә. Аның төп әһәмияте – алдаткыч булуда, камиллеккә омтылыш тудыруда.

Менә монда инде безнең җитешсезлекләр хәрәкәткә килә һәм тормышны алга этәрүче көчкә әверелә.

Борынгы заманда ике хатын яр буенда суга карап утыра. Берсе, судагы чагылышын күреп, күршесенә күз ата. «Кара әле, мин аннан ямьсезрәк икән бит», – дип уйлый. Шуннан күршесе кебек үк чибәр булырга теләп, яр буендагы учактан күмер алып килә дә кашларын каралтып куя. Аннан күреп, күрше хатынның да башы эшли башлый: «Шушы маймылны да матурлагач, бу күмер кисәге мине бөтенләй гүзәлгә әйләндерәчәк бит», – дип, ул да учак янына китә… Шул рәвешле бизәнү сәнгате үсеп чыга. Адым саен елга буена йөгермәс өчен, ирләренә көзгә уйлап табарга кушалар. Алгарыш хасил була.

Ике ир арбага агач төйи. Берсе көчле, юан бүрәнәләрне уртасыннан тотып кына илтеп сала. Икенчесе бүрәнәнең башта бер башын күчерә, аннан икенчесен. Төягәндә дә шулай күтәрә. Бер мәлне башы эшләп китә дә үзе кебек үк этләнүче берничә иптәшен чакыра: «Әйдә, башта минем арбаны тутырыйк, аннан сезнекен төярбез». «Бер, ике, өч. Бердәмлектә – көч!» дип кычкыралар бүрәнә күтәргәндә. Шул рәвешле, теге кешенең көчсезлеге үзе кебекләрнең берләшүенә китерә. Бу күренеш бүген дә хәрәкәттә: көчлеләр, гадәттә, көтү белән йөрми, ә көчсезләр һәрчак бердәм була.

Йөк кранын пәһлеваннар уйлап тапкандыр дип уйламыйм. Самолетны – кошлар, корабны балыклар уйлап тапмаган. Яхшы кулларга килеп эләккән һәрбер җитешсезлек уңышка ирешү чарасына әверелергә мөмкин.

Әйтеп кенә бактым

Пардон

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне телевизордан электр самокатларында йөрүчеләр өчен яңа кагыйдәләр булдыру кирәклеге турында сөйләделәр. Сүзләр арасында колакка ят тоелганнары да бар иде. Шундыйларның берсе «кикшеринг». Ул кыска вакытка арендага самокат биреп торуны аңлата икән.

Бер уйлаганда, руста да, татарда да күп кенә сүзләрне үзебезчә аңлатырга тел байлыгы җитә, әмма, ни сәбәп, читтән кергән һәр нәрсә безгә әллә нинди серле, гаҗәп тоела. Чит сүзләр куллану безнең өчен мәдәнилекнең иң югары ноктасы кебек.

Казан телевидение студиясендә эшләгән чак бу, бер режиссер тәҗрибә уртаклашыргамы шунда, чит илгә барып кайтты. Озак тормады ул анда, күп булса, 10 көн тирәседер. Шул аз вакыт эчендә генә дә тел шомартып кайтты. Сөйләшкәндә җөмлә саен диярлек «Окей» дип кыстыра. Һәм «окей» чире бер-ике көн эчендә безгә дә йогып өлгерде. Әлбәттә, һәр тел башка телләр хисабына байый, тулылана һәм бу табигый. Әмма без бүген, кирәксә-кирәкмәсә дә, чит сүзләр кыстырып, телебезне чүпләп бетерә башладык.

Украинада махсус хәрби операция башлангач, рус телен саклау, рус дөньясын аякка бастыру кирәклегенә төшендек. Россия Федерациясендә дәүләт теле турындагы законга үзгәрешләр дә тәкъдим ителде. Президент Владимир Путин аңа кул да куйды. Закон буенча, хакимият органнары вәкилләре, төрле дәрәҗәдәге түрәләр үз вазыйфаларын башкарганда хәзерге рус әдәби теле нормаларыннан читләшергә тиеш түгел. Шул ук вакытта оятсыз сүзләр белән сөгенү дә тыела. Чит сүзләрне аларның русча синонимнары булмаган очракта гына куллану рөхсәт ителә. Законга өстәмәләрнең кыскача эчтәлеге менә шундый. Пардон, кәнишне, ә менә чит сүзләрнең кайсын кулланырга ярый, кайсын ярамый икәнен ничек ачыкларга соң? Закон проектын эшләүчеләр бу турыда да кайгырткан, әдәби тел нормалары буенча яңа сүзлекләр, белешмәләр чыгарга тиеш. Закон быел февральдә үз көченә керде, әмма норматив-хокукый актлар проектына лингвистик экспертиза үткәрүләр шактый вакытны алачак, диләр.

Димәк, закон үтәүгә 2025 елдан гына чын-чынлап тотынырбыз. Игътибар иттегезме, соңгы ике җөмләдә генә дә күпме чит ил сүзе бар. Алар инде кулланылышка күптән кергән сүзләр, димәк, тыелмаслар. Тик менә татарда «исемен җисеме» дигән сүз бар бит, ягъни мәсәлән, һәр чит сүз җәмгыятьтәме, икътисадтамы, яшәешебездәме, яңалыклар, үзгәрешләр белән бергә килеп керә. Димәк, тел саклау өчен без дөньясында алдарак барырга тиештер әле, күп өлкәләрдә диюем. Пардон, кәнишне, менә монысы бик ансат булмас.

Күптән түгел телевизордан тагын бер гыйбрәт карадым. Таплы болан (пятнистый олень) үрчетүче бер абзый, элек боланның койрыгы – Япониягә, тиресе – тагын нииндидер илгә, мөгезе, тоягы – Кытайга, ите тагын каядыр китә иде, безгә эчәкләре генә кала иде, дип сөйләп торды. Инде менә хәзер боланны тулысынча үзебездә калдырып, гәүдәсенең төрле өлешләреннән төрле файдалы әйберләр җитештереп булмас микән, дип хыяллана бу. Әлеге әйберләр русча аталып, чит илләргә дә чыгарыла башласа, иллә дә шәп булыр иде, җисем белән бергә читкә русча исем дә чыгар иде. Пардон, чагыштыруым бик уңышлы түгелдер дә, әмма һәр зур эш кечкенә эшләрдән башлана бит. Ә «пардон» дигән сүзне кулланганга үпкәләмәгез, яме. Ул рус теленә Петр I заманнарында ук, ягъни Россиягә Көнбатыш культурасы йогынтысы көчәйгән вакытларда ук килеп кергән, Петр патша Россияне Европа культурасына якынайту өчен җан атып яшәгән бит.

Ә без хәзер үзебез булып, үзебезчә яшәргә омтылабыз. Так што, тагын бер кат, пардон!

АЧЫ БАЛАН ТӘМЕ

ӘНИЛӘР КӨНЕ УҢАЕННАН УЙЛАНУЛАР

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов / Фото бизәү өчен бирелә

Кайвакыт оныкларның әниләрен (кызым белән киленемне) кочканнарын күзәтәм. Сабый мәхәббәте тирән һәм риясыз, ул әлегә бу дөньяның матди яклары белән дә, башка прагматик максатлар белән дә чуптәнмәгән. Әмма бер нәрсә хак: еллар үткән саен, бала яратуы кими, аналарда бу хис арта.

Бигрәк тә әни олыгаеп, бала ярдәменә мохтаҗ була башласа, хәл үзгәрә: әни дигән авыр йөкне тартасы килми, ул авыр сынауга әверелә. Картлар йорты дигән исеменнән үк йөрәккә салкын йөгерә торган урынга мохтаҗлык барлыкка килә. Гыйбрәт өчен генә белешеп карасак, без ул йортларда буш урыннар юклыгын, зур чират икәнен белер идек. Әти-әниле балаларның башка гаиләләрдә тәрбияләнүе дә хәзер сирәк хәл түгел. Иманнан баш тарткан секуляр җәмгыятьләрнең зур бәласе болар.

Тагын бер нәрсә бар: әнигә булган мохтаҗлык аны бер тапкыр да күрмәгән балалар йөрәгендә зур урын ала. Аз гына мөстәкыйль затка әверелүгә, алар төрле юллар белән хәзерге телдә «биологик әни» дип аталган кешене эзли башлый. Йөрәкне тетрәндерә торган бик күп сюжетлар туа. Социаль челтәрләрнең берсендә бер кызның еллар буе үз әнисен эзләве турындагы постлары белән танышырга туры килде. Яхшы гаиләдә тәрбияләнеп үскән ул. Тугач ук, үзләренеке итеп рәсмиләштергәннәр дә җил-янгыр тидерми үстергәннәр. Тәрбиягә алган ана белән бала арасында аеруча якын дуслык булган. Әмма йөрәге белән барыбер үзенең бу гаиләнеке түгеллеген тойган. Яшерсәләр дә, үзенең тәрбиягә алынган чит бала икәнен ачыклаган. Аңа хәтта ЗАГС хезмәткәре әйтеп караган: «Менә бит синең туу турындагы таныклыгың туган көндә үк рәсмиләштерелгән, уллыкка алынган балаларның алай булмый ул», – дигән. Әмма кыз дөреслекне ачыклау уеннан кире кайтмаган. Тәрбияләп үстергән әнисе, кинәт авырып, үлем сәгате якынлашкач кына аңа серне ачкан: бер студент кыз, алдан килешеп, бала тугач та, аны гаиләгә тапшырып, юкка чыккан. Шуннан кыз үз әнисен эзләп табу өчен, яңа технологияләргә мөрәҗәгать иткән: ДНК анализы аша биологик ананы табарга теләгән. Интернетта хәзер бу эштә ярдәм итүче махсус сайтлар бар икән. Күзәнәктә язылган кодлар аның татар кызы булуын ачыкларга ярдәм иткән, әнисенең Татарстаннан булуы да сер булудан туктаган (кыз үзе Мәскәүдә үскән) һәм, ниһаять, җепнең очы безнең Арча районында яшәүче хатын-кызга барып тоташкан. Ана белән бала очрашкан, интернетта фотолары да бар, әнисе начар кеше түгел икән, гафу да үтенгән. Әти кеше вафат икән инде. Кызның аңа охшавын да әйткәннәр.

Җәмгыять технологик яктан алга барган саен, мондый хәлләр ешрак очрый. Сәбәбе билгеле: кешеләр бу дөньяның сынау гына икәнен белми һәм яшәгәндә дөньядан барысын да умырып калырга тырышалар. Рәхәт яшим дисәң, бала да, әти-әни дә йөккә генә әйләнә бит инде, табигый хисләр онытыла. Аллаһы Тәгалә исә үзенең Китабында ана дигән затны бик югары күтәрә... Анага хыянәт итү мәңгелек тормышны югалтуга тиңләштерелә. Аналарга эшләнгән изгелек Аллаһка якынайтучы һәм адәм баласын коткаручы иң зур нәрсә икәнлеге ассызыклана. Адәм балалары адаштыручы идеологияләр ярдәмендә бу хакыйкатьтән ераклаштырылгач, фаҗига үзен озак көттерми: әниләрне кире кагучылар мәйданга чыга. Кешеләрнең күзен ачу өчен, намуска өндәгән тетрәндергеч әдәби әсәрләр туа башлый. Сюжетлары тормыштан алынган ул әсәрләр зур тәрбия әһәмиятенә ия, билгеле, әмма барыбер иманга нигезләнгән кыйммәтләрне алыштыра алмыйлар. Без балачакта Шәриф Хөсәеновның «Әни килде»сен («Әниемнең ак күлмәге») телевизордан карап үстек. Драма бик популяр иде. Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре теманы башка юнәлештәрәк иңли, киңрәк колачлый, ул да йөрәккә үтеп керә.

Бу темага алынгач, Василий Шукшинның «Калина красная» повестен яңадан укып чыктым. Күз алдында шул повесть буенча эшләнгән кинофильмның бер эпизоды торды. Рецидивист карак Егор Прокудин, төрмәдән чыккач, күп еллар буе күрешмәгән әнисе янына барып чыга. Үзенең кем икәнен әйтми. Ана Егорның төрмәдә утырганда хат аша танышкан хатыны Любага үзенең сугышта үлгән балалары һәм 18 ел элек югалган улы турында сөйли. Кара күзлек кигән улының үзен тыңлап утыруын белми. Беләсезме: нәфис фильмдагы бу эпизод документаль бит, анда актриса түгел, чын ана чыгыш ясый. Кино төшерә башлагач, Куделиха карчыкны уйнарга тиешле актриса авырып китә, әмма авылда шундый ук язмышка ия булган бер карчык булуын әйтәләр. Карчыкны яшерен камера белән төшереп алалар һәм аның чын фаҗигасе кинофильмга эпизод булып кереп китә. Картинаның иң тетрәндергеч урыны да шул инде. Соңыннан Шукшин карчыкның өен үз кулары белән сипли, кышка утын әзерләп бирә, берникадәр акча калдыра. Карчык күршеләренә үзенең югалган улы шул Шукшин икәнен сөйләп йөри. Әдәби әсәрдәге Егорга исә, «кеше кыяфәтенә кереп», әнисе янына кайтырга насыйп булмый, аны элекке «дус»лары үтерә.

1974 елда Бакуда узган бөтенсоюз кинофестивалендә төп приз өчен ике картина көрәшә: Быковның «В бой идут одни старики» фильмы һәм Шукшинның «Калина красная» картинасы. Чиновниклар Шукшин фильмын икенче урынга калдырырга ниятли, әмма бу хакта ишеткәч, Быков: «Минем картинам – сугыш турындагы чираттагы бер фильм, ә Шукшинныкы – моңарчы үтеп керү түгел, уйларга да тыелган зонага бәреп керү», – дип, Гран-придан баш тарта. Фильмның фокусы, минем уйлавымча, Егорның үз әнисе Куделиха карчык белән яшерен очрашуын сурәтләгән эпизодта. Аның уйналмыйча, картинага чын тормыштан килеп керүе сюжетны икеләтә көчле итә. Егор үлеме алдыннан Любага калдырган акчаны, икегә бүлеп, әнисенә илтергә васыять әйтә.

Ана – бала мөнәсәбәтләрен тотып торырга тиешле төп нигез юк ителгәч, тормыштан бәхет кача, аннан ачы балан тәме килә башлый. Әсәрне кабат укыганда, шул турыда уйландым.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИДЕЛ БИТ УЛ... САЙ БИТ УЛ

Татар халык җырының сүзләрен әнә шулай үзгәртергә туры килмәгәе. Хәер, быел Иделгә карагач, бер дә җырлыйсы килми. Елга күзгә күренеп саекты. Аңа ияреп, башка елга-сулыкларның да ярлары кипте. Мәсьәлә ил күләмендә күтәрерлек хәлгә җитте. Яр буйларын кар каплады, тик мәсьәлә хәл ителмәгән. Идел суы кая киткән? Бу сорауга җавап эзләгән саен, сораулар күбрәк туа.

«Татар-информ»

Гади елга түгел

Аккан су юлын эзли башлаганчы, Иделнең суны кайдан алуын да әйтик.

– Елганың якынча 10 проценты – яңгыр суларына, 30 проценты чамасы – җир асты чишмәләренә, калган өлеше, ягъни 60 процентка якыны кар суларына туры килә, – ди биология фәннәре кандидаты Әлфия Сәетова. – Идел югарыда Валдай калкулыгында башлана һәм түбәнгә – Әстерханнан Каспий диңгезенә коя. Татарстан территориясенә аның урта өлеше туры килә.

КФУның табигатьне тергезү һәм су ресурсларын файдалану кафедрасы ассистенты, эколог Наил Назаров әйтүенчә, Идел дигәч тә, тарих битләрендә телгә алынган табигый елганы гына күз алдына китерү дөрес түгел.

– Идел – рәттән килүче сусаклагычлар системасы. Татарстанга Куйбышев сусаклагычының бер өлеше туры килә. Ул – Идел акваториясендә генә түгел, ә ил күләмендә һәм Европада мәйданы, күләме буенча иң зурысы. Сусаклагычларның һәркайсының үз су режимы бар. Суның күләме энергетика, балык үрчетү тармагы кебек өлкәләргә дә, гади халык ихтыяҗына да бәйле. Идел – эчә торган су чыганагы да. Бу – тулысынча кеше тарафыннан контрольдә тотылучы ясалма экосистема, – ди белгеч.

Әлеге сүзләр белән Татарстан Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты директоры урынбасары Дмитрий Иванов та килешә.

– Идел елгасындагы суның күләме кеше эшчәнлегенә бәйле, – ди галим. – Шуңа күрә елга саекмый, ә Куйбышев сусаклагычында су дәрәҗәсен киметәләр. Нормативлар буенча биредә су биеклеге Балтыйк системасы буенча 53 метр тәшкил итәргә тиеш. Әмма бүген әлеге күрсәткеч – 51 метр дәрәҗәсендә. Шул ук вакытта, 49 метр куркыныч чик булып санала.

Идел – Кама сусаклагычлары каскадына 13 гидроузел һәм 12 гидроэлектростанция керә. Сусаклагычларның эш тәртибен Су ресурслары федераль агентлыгы контрольдә тота.

«80 миллион кешегә кагыла»

Җәй азагыннан бирле Идел күзгә күренеп саекты. Белгечләр әйтүенчә, октябрьдә Куйбышев сусаклагычындагы су биеклеге күпьеллык күрсәткечләрдән 1,5 метрга түбән төшкән. Урта Идел төбәкләренең барысы да пошаманда. Сентябрьдә Татарстан, Мари Эл, Чувашия республикалары, Самара һәм Ульяновск өлкәләре җитәкчеләре, борчылу белдереп, Россия Президенты Владимир Путинга да мөрәҗәгать итте хәтта. Эш шунда ки, Куйбышев сусаклагычына секундына 4 мең куб метр су керә. Бу җәйдә түбән Идел төбәкләренә секундына 4,5 – 5 мең куб метр су аккан. Белгечләр фикеренчә, су күпме керә, шул кадәр агып чыгарга тиеш.

– Татарстанда Куйбышев сусаклагычының саегуы аркасында социаль киеренкелек саклана, – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә узган киңәшмәләрнең берсендә. – Суның тирәнлек күрсәткече түбән булу сәбәпле, суднолар Идел һәм Чулман елгалары ярында урнашкан биш торак пунктка барып җитә алмый. Куйбышев сусаклагычының республика территориясендә аз сулы булуы «Бөек Идел юлы» төбәкара проектының төп бурычларын үтәргә комачау итәргә мөмкин.

Идел һәм Дон елгалары бассейннарында су кимү мәсьәләсе ноябрь башында Россия Дәүләт Думасында кат-кат һәм шактый кискен яңгырады.

– Болай булмый, – диде Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин пленар утырышта. – Идел – кешеләр тарафыннан иң нык көйләнелүче елга. Шуңа күрә аның ни өчен саегуына тәгаен җавап булырга тиеш. Әлеге мәсьәлә Идел буенда яшәүче 80 миллионнан артык кешегә кагыла.

Вячеслав Володин сүзләренә караганда, елганы «акылсыз көйләү»гә прокуратура тарафыннан тиешле бәя бирелергә тиеш. Суны түбән Иделгә агызу Волгоград һәм Әстерханга әллә ни ярдәм итмәде, ә менә Идел буендагы башка төбәкләрне кыен хәлдә калдырды, дигән фикер әйтте Вячеслав Володин. Депутатлар әлеге мәсьәлә уңаеннан ил Хөкүмәтенә дә мөрәҗәгать итте.

Дәүләт Думасы комитеты утырышында Татарстанның экология һәм табигый ресурслар министры Александр Шадриков Куйбышев сусаклагычы ярында сусыз утырып калган 10 миллион кеше исеменнән чыгыш ясады.

– Без су ресурсларыннан файдалану кагыйдәләрен тиешенчә үтәүне сорыйбыз. Үз вакытында иң акыллы кешеләр Идел – Кама гидроэлектростанцияләре каскадын төзегән, алар ук бу кагыйдәләрне кабул иткән, – диде министр. – Әлеге мәсьәлә Куйбышев сусаклагычы ярларында урнашкан биш төбәктә яшәүче 10 миллионга якын кешегә кагыла. Куркыныч бар, елгада купсанлы утраулар пәйда булды. Шуңа күрә без әлеге мәсьәлә белән шөгыльләнергә тиеш. Гидроузеллар эшендә сакчыллык зарур. Язгы ташуга кадәр Куйбышев сусаклагычын тутырырга кирәк.

Үз фикерен саннар белән дә дәлилләп күрсәтте ул. Күл һәм елга балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының Татарстандагы бүлеге мәгълүматларына караганда, Идел саегу аркасында быел Куйбышев сусаклагычында балык уылдыгының 70 проценты юкка чыккан. Вазгыятьне уңай якка үзгәртү өчен, Александр Шадриков җәйге чорда су ресурсларын туплау мөмкинлеген тәэмин итүче түбән басымлы гидроузеллар төзергә тәкъдим итте.

Көймәң комга терәлсә

Иделнең саегуына китергән төп сәбәпләрнең берсе итеп бу җәйнең артык эссе һәм коры булуын атыйлар. Синоптиклар мәгълүматларына караганда, июньдә, мәсәлән, айлык норманың алтыдан бер өлеше кадәр генә яңгыр яуган. Июль исә аномаль эссе булды.

– Быелгы корылык нәтиҗәсендә Идел һәм аңа кушыла торган зур һәм кечкенә елгалар тиешле су күләмен җыеп бетерә алмады, – ди эколог Наил Назаров. – Су җитмәгәч, гидроэлектростанцияләр аны тагын да күбрәк сарыф итәргә мәҗбүр. Нәтиҗәдә без Иделнең тагын да ныграк саегуын күзәтәбез. Ягъни бүгенге вазгыять елгада су җитмәүгә генә бәйле түгел, аңа ихтыяҗ да арта. Гидроэлектростанцияләр төзелгән узган гасырның 50–60 нчы еллары белән чагыштырганда, бүген суны күбрәк кулланабыз. Аңа ихтыяҗ зуррак. Бу исә мәсьәләне тагын да катлауландыра. Климат үзгәрү Иделнең саегуына тәэсир итә, билгеле. Әмма мин бер генә факторны аерып карау дөрес түгел дип саныйм. Шул ук сәнәгать предприятиеләренә Идел елгасының су җыю бассейнына керүче кечкенә елгалардан су алалар да, технологик процессларда соңаны, чистартып та бетермичә, кире сулыкларга агызалар. Бу да Иделнең саегуына һәм сыйфатына тәэсир итә. Агачлар күпләп киселә. Кечкенә елгалар кипмәсен өчен ул да бик мөһим.

Ничек кенә булмасын, экологик афәт турында сөйләргә иртәрәк, ди белгеч.

– Монда күбрәк экологик кризис күзәтелә. Чөнки бүгенге хәлләр иң беренче чиратта елгалардагы биологик ресурсларга зыян салачак. Иделнең саегуы яз көне бигрәк тә куркыныч, чөнки бу чорда балыклар үрчи. Гадәттә, язгы ташу вакытында су күп була. Сулыкларның мәйданнары да арта. Балыклар ярдан ерак түгел, тирән булмаган урыннарда уылдык чәчә. Тик җәй башында суны күпләп агыза башлагач, балыкларың уылдык чәчкән урыннары ачыклыкта кала һәм кибә. Мәсьәләнең икенче ягы да бар: су дәрәҗәсе түбән булган елларда башка чара юк. Чөнки без суны алга таба төшермәсәк, бу агымсу буенча түбәндәрәк урнашкан сусаклагычларда чагылыш табачак. Мәсәлән, бездән соң Саратов сусаклагычы урнашкан, димәк, анда су тагын да азрак булачак. Шул ук Волгоград сусаклагычын алсак, анда кыйммәтле мәрсин балыклары уылдык чәчә. Ул Каспий диңгезеннән күтәрелгән балыкларның үрчү төбәге булып тора. Түбән Иделдә су дәрәҗәсе кимү тагын да зуррак зыян салырга мөмкин, – ди Наил Назаров.

Иделне дә, безне дә кыш коткара алыр иде. Кар сулары күп булып, елга ярларыннан ташысамы?! Синоптиклар гына быел кыш бик кыска булырга мөмкин, ди. Чү, юрап китерә күрмик.

Фикер

Азат ЗӘЙНЕТДИНОВ, «Кама» суднолар йөртү компаниясенең генераль директоры урынбасары:

– Иделдә су саегу аркасында, көймә комга утыра. Соңгы тапкыр мондый хәлне 2010 елда күзәткән идек. Тик быел су дәрәҗәсе тагын да түбән төште. Моңарчы без 4 мең тонна чамасы йөк төяп йөрсәк, хәзер икеләтә азрак ташыйбыз. Яр буена кайтып җиткәч тә, якын килеп булмый. Йөкнең яртысын әчтә бушатырга, аннары гына причалга килергә туры килә. Икеләтә эш дигән сүз бит бу. Иделнең саегуы безгә бик күп мәшәкать китерде. Кышка суднoларны куярга да тирән урын эзләргә кирәк. Элек ярдан ерак түгел генә тукталсак, хәзер әчкәрәк керәсе. Бу уңайдан, киләсе навигация чорына кадәр су дәрәҗәсе 45,8 метрга кадәр төшәргә мөмкин дигән кисәтү дә килде. Әнә шуннан чыгып, үзегез чамалагыз. Нишләтәсең, гидроэлектростанцияләр – барысы да энергетиклар кулында. Ә аларга электр энергиясен сату безнең борчу-мәшәкатьләргә караганда мөһимрәк.

АШАГАНЫҢ – АШМЫ?

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ СЫРЛАРНЫҢ СЫЙФАТЫН ТИКШЕРДЕ

Без нәрсә ашыйбыз? Ни өчен үзебездә җитештерелгән сыйфатлы товар кибет киштәләренә барып җитми? Әлеге сорауларга җавап табар өчен, «ВТ» хәбәрчесе белгечләр белән аралашты һәм сырларның сыйфатын тикшерүдә катнашты.

Сыйфат

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов сүзләренчә, без кибеттән сатып алып ашый торган продукция сыйфаты елдан-ел начарая. Әйтик, быелның тугыз аенда кибет киштәләренә куелган социаль әһәмияткә ия товарларның (сөт һәм сөт ризыклары, ит һәм ит продуктлары, икмәк, колбаса, балык) 21 проценты тиешле таләпләргә җавап бирмәве ачыкланган. Бу юлы без мисалга сырны алырга булдык һәм белгечләр белән бергә тәмена карап бәя бирдек.

Росстат мәгълүматлары буенча, Россиядә сыр җитештерү 3 процентка якын кимегән. Аның каравы «сыр продукты» эшләү 14 процентка арткан. Димәк, әлеге продуктка үсемлек майлары күп кушыла, дип аңлата белгечләр. Татарстанда исә елына 30 мең тонна сыр һәм сыр продукты җитештерәләр. Кибет киштәләрендә 300 атамалы сыр сатыла.

Дегустациядә, ягъни тәмена карап бәя бирүдә халык арасында аеруча популяр булган «Россия» һәм «Голландия» сырлары тәкъдим ителде. Белгечләр арасында технологлар, сөт комбинатлары җитәкчеләре, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, тикшерү органнары вәкилләре бар иде. Сырларны исә Казанның популяр сату урыннарыннан, ягъни халык күп йөри торган кибетләрдән, базарлардан алганнар.

– Сырдан «сыр продукты»н аеру гади кеше өчен бик кыен. Аны бары тик лаборатория тикшерүләре нәтиҗәсендә генә ачыклап була. Ялганны чыннан аерып булмасын өчен, технологияләр бик алга китте. Һәм бу барлык төр ризыкка да карый, – ди Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова.

Чыннан да, сырларны авыз итүчеләрнең бәяләмәләре Татарстанның гигиена һәм эпидемиология үзәге лабораториясе нәтиҗәләренекеннән шактыйга аерылды. Күпчелек белгечләр

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сырның сыйфатын ничек тикшерергә?

1. Сырның тишекләре («күз»ләре) ачык һәм зур булырга тиеш.
2. Тышы тигез һәм юка.
3. Сыр уртача катылыкта булырга тиеш. Аның артык йомшак булуы – өлгереп җитмәвен яки үсемлек майларын күп кушуны, каты булуы тиешле вакыттан озаграк тотуны аңлата.
4. Сырда «сыр» дигән язу булу мөһим.
5. «Россия» сыры тигез, ак һәм ачык сары төстә булырга тиеш.
6. Гадәти сырда күгәрек булырга тиеш түгел.
7. «Россия» сырында бераз гына әчкелтем тәм булу хуплана.

мактаган, яхшы дип санаган сыр фальсификат дип табылды. Һәм шунысы гаҗәпләндерде: үз продукциясен җитештерүчеләр дә танымады.

– Без бүген тикшерүгә 40 төрле сыр сайлап алдык. Дегустациягә аларның иң яхшы дигән унтугызын сайладык, алар арасында чын сыр булмаган берничә продукт та бар иде. Барлык сайлап алган сырлар арасында 12се, ягъни 30 проценты ялган булып чыкты. Узган ел бу күрсәткеч 23 процент иде. Сырларда үсемлек маеның күп кулланылуы, продуктның майлылыгы аз булу, шулай ук кулланучы өчен тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве ачыкланды, – диде Розалия Арсланова.

Сәбәп нидә?

Ни өчен сыйфат төшә соң? Сөт ризыклары җитештерүчеләр иң сыйфатлы, яхшы сөтнең республикадан читкә китүен төп сәбәп дип атады.

– Яхшы сыр өчен төп алшарт – чимал. Әгәр бик шәп сөт була икән, сыры да, башкасы да шулай ук шәп булачак, – диде сыр җитештерүче бер предприятиенең генераль директор урынбасары Юлия Тарасова. – Тик безнең кебек җитештерүчеләр өчен Татарстанда яхшы сөт юк. Беренче чиратта аларны зур оешмалар сатып ала. Аларда товар әйләнеше бик тиз бара. Ягъни бүген сатып алган сөтне алар иртәгә яхшы бәядән сатып та җибәрә ала. Ә сыр белән хәлләр башкачарак, чөнки аңа өлгерергә вакыт кирәк. Гомумән, сыр сөт ризыкларын әзерләүдә иң катлаулы продукт булып санала. Ул 60 тәүлек дәвамында өлгерергә генә тиеш. Ингредиентларга килгәндә, без чит ил компанияләре белән элек ничек эшләгән булсак, хәзер дә шулай ук эшлибез. Ләкин күпчелегебез оеткыга күчте. Ә чит илләрдән кайтарылган каплар эчендә нәрсә булганлыгын без берничек тә белә алмыйбыз. Әлеге илләр безгә сыйфатлы продукт җибәрәдер дип уйламыйм. Кызганыч, шулай дип уйларга җирлек бар. Совет заманында бөтенләй башка хәл иде. Оеткыны да без үз кулларыбыз белән эшләдек. Хәзер ул фабрикаларның берсе дә юк.

Җәүдәт Әхмәтханов үзебездә җитештерелгән яхшы продуктларның федераль кибет челтәрләренә барып җитә алмау мәсьәләсен дә кузгатты. Аларда сатыла торган продукциянең 80 проценты читтән кайтарылган. Төп сәбәп – үзебезнекеләрнең кыйммәт булуында. Сүз уңаеннан, дегустациядә яхшы дип табылган сырларның да күпчелеге башка төбәкләрнеке иде.

Розалия Арсланова исә яхшы сырның берничек тә арзан була алмавын әйтте. Ул никадәр арзанрак, шуның кадәр күбрәк үсемлек мае кушылганны аңлата. Яхшы сырның бер килосы

БЕР КЕШЕГӘ СӨТ РИЗЫКЛАРЫН КУЛЛАНУНЫҢ ТИЕШЛЕ НОРМАСЫ (ЕЛЫНА)

Продукт	Норма
1,5–3,2 процентлы сөт, кефир, йогырт	50 кг
0,5–1,5 процентлы сөт, кефир, йогырт	60 кг
Эремчек	9 кг
Сыр	6 кг
Атланмай	4 кг
Кибет каймагы	4 кг



Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча

КАЙСЫ СӨТ РИЗЫКЛАРЫ АРАСЫНДА ЯЛГАННАРЫ ЕШРАК ОЧРЫЙ?

Роспотребнадзор мәгълүматлары буенча

якынча 500–600 сум торырга тиеш дисә, җитештерүчеләр аның бәясен бөтенләй 1000 сум тирәсе дип бәяли. Тик халыкның күпчелеге мондый бәядән сыр сатып алырга әзерме соң?

– Без тикшергән сырларны бик начар дип әйтәсе килми, сыйфатлары буенча алар уртача. «Голландия» һәм «Россия» сырлары – көндәлек тормышта еш кулланыла торган ризык. Алардан әллә ни көтәргә дә кирәкми. Гади сатып алучыга беренче чиратта тәме һәм бәясе, аннан соң сыйфаты кирәк, – диде бу уңайдан Юлия Тарасова.

Аның сүзләренә караганда, товарны сатып алганда аның төрелмәсенә дә игътибар итәргә кирәк. Теләсә нинди марканы ялганлап сатып була.

Фермерныкы яхшырак

Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров әйтүенчә, республикада сыр җитештерүче берничә зур кооператив бар.

– Сату белән проблемалары юк. Нурлат эшмәкәре үз продукциясен – бөтен Идел буе округына, «Наурүз» кооперативы Россия буйлап тарата. Шулай ук алар Татарстанда фермер продукциясен зур булмаган кибетләрдә дә саталар. Алардан башка да җитештерүчеләр бар. Гомумән, әлеге көндә фермерлар җитештергән товарларны «Перекресток» кибетенә тапшыру буенча зур килешү әзерләнә, – диде ул.

Аның фикеренчә, авырлык – товар әйләнешендә.

– Безнең сыйфатка шигебез юк. Зур оешмаларда җитештерелгән товарга караганда безнең кооперативларда әзерләнгәне яхшырак, әлбәттә. Әлегә кооперативлар үз мөмкинлекләренең 30 процентын гына куллана, чөнки сәүдә челтәрләре белән эшләүдә авырлык бар, – диде ул.

Камияр Байтимеров сүзләренчә, хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә экологик чиста продукт җитештерү өчен программалар комплексы эшләнә. Әлеге эш барышында нибары унбер район җирлегендә генә экологик чиста продукт җитештереп булуын ачыклауларын әйтте. Тик әлегә ул районнар сер булып саклана икән. Шуңа күрә әлеге темага тагын бер әйләнеп кайтырбыз дип уйлыйбыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

РКБ БАШ ТАБИБЫ РАФАЭЛЬ ШӘВӘЛИЕВ:
«БЕЗГӘ ҺӘР ГОМЕР КАДЕРЛЕ»

Халыкка вакытында тиешле ярдәм күрсәтелде, бик күп кешенең гомере саклап калынды. Республика клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ узып баручы елның төп нәтиҗәсе дип шуны атый. Уникаль операцияне кем ясый? Табибның абруе нәрсәгә бәйле? Балалар күбрәк тусын өчен, ни эшләргә? Баш табиб белән бу һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

:: Бүген РКБ – әйдәп баручы медицина оешмасы. Күп кенә уникаль операцияләр дә нәкъ менә биредә ясала. Шуңа күрә Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләргә барасы юк. Бу дәрәҗәгә ирешүнең төп сере нидә? Узып баручы елны нинди нәтиҗәләр белән йомгаклыйсыз?

– «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектында күрсәтелгән барлык бурычларны үтәп, төп күрсәткечләрне яхшырттык. Иң мөһиме – халыкка вакытында тиешле ярдәм күрсәтелде, бик күп кешенең гомерен саклап кала алдык. Елга иң төп нәтиҗә әнә шулдыр. Бүген Республика клиник хастаханәсендә көчле команда эшли. Безнең белгечләр клиника кысалары белән генә чикләнми, республиканың башка оешмалары белән дә хезмәттәшлек итә. Хастаханә үзе генә сыйфатлы, нәтиҗәле эшли алмый. Замана таләбен дә истә тотарга кирәк. Бүген медицина ярдәме бик тиз күрсәтелергә тиеш. Көтеп утырып булмый. Без гадәттән тыш хәлләргә дә әзер булырга тиеш. Шуңа күрә бездә санавиация, реанимобиль, күчмә хастаханә, мобиль диагностик ресурслар бар. Бу, үз чиратында, табибларга булган таләпне дә арттыра. Безнең белгечләр даими рәвештә белемнәрен күтәреп тора. Мәскәүдә дә, чит илгә китеп тә укыйбыз. Хастаханәдәге һәрбер бүлек мөдире инглиз телен белә. Бездә эшләүче һәр табибның үзенең укучылары бар. Алар бездә стажировка узып, районнарда эшли.

:: Гадәттән тыш хәлләр, димәктән, республика клиник хастаханәсендә ясалган уникаль операцияләргә дә тукталып китик әле...

– Алар бик күп. Әле күптән түгел генә җитештерүдә эшләгәндә тәненең 90 проценты пешкән ир-атның гомерен саклап калдык. Андый чакта үзебезнең кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз. Чит төбәкләрдәге хезмәттәшләр белән элемтәгә кергән чаклар да була. Берничә көн элек кенә 38 яшьлек бер егетне Төмәнгә җибәрдек. Аның баш миендә шеш иде. Төмәндә федераль нейрохирургия үзәге җитәкчесе, академик, дөньядагы иң яхшы нейрохирургларның берсе, якташыбыз Альберт Суфианов эшли. Алар, бик нечкә эндоскоп һәм манипуляторлар кулланып, катлаулы операцияләр ясый. Гомумән, уникаль операцияне бер кеше генә эшли алмый. Төрле дәвалау оешмаларында эшләгән, төрле юнәлештә эшләүче табибларның уртак хезмәте һәм тырышлыгы нәтиҗәсе ул.

:: РКБда дәваланырга башка төбәкләрдән килүчеләр аз түгел.

– Әйе, безгә чит төбәкләрдән дә бик күп киләләр. Мәскәү, Чувашия, Ульяновск, Башкортстан, Удмуртиядән килүчеләр шактый. Удмуртиядән берничә табиб та безгә эшкә күчте. Мәскәүдән күченеп кайткан табибларыбыз да бар. Бу – бер безнең генә түгел, бөтен Татарстанның дәрәҗәсе, абруе югары дигән сүз. Бүген республика медицинасы, гомумән, бик югары бәяләнә.

:: Районда яшәүчеләр белән элемтә ничек урнаштырылган? Бу юнәлештә нинди яңалыкларыгыз бар?

– Район, авыл җирендә бүген бик күп эшләр башкарыла. Татарстанда яшәүче һәр кешегә беренче ярдәм вакытында күрсәтелергә тиеш. Министрлык тарафыннан куелган иң беренчел бурычларның берсе ул. Моның өчен мөмкинлекләр булмаган җиргә күчмә хастаханәләр килә, мөмкинлекләр булган урыннарга да таләпләр югары. Анда диагностик җиһазлар булырга, анда эшләүче табиблар даими рәвештә укып, белемен арттырып торырга тиеш.

РКБның матбугат үзәге

> Болар бар да авыру вакытында табылсын өчен эшләнә. Ник дигәндә, чир никадәр иртәрәк табылса, аны дәвалау ихтималы да арта. Шул рәвешле бу безгә очсызгарак та чыга. Бүген районнарда яшәүчеләргә биш мобиль поликлиника хезмәт күрсәтә.

:: Коронавирус барыбыз өчен дә зур сынау булды. Бу сынауны лаеклы рәвештә уздык, дип әйтә аласызмы? Ковид безне нәрсәгә өйрәтте?

– Безнең тормыш һәрчак өйрәнүдән тора. Ковид кына түгел, яңа туган һәр көн безне нәрсәгә дә булса өйрәтә, яңа сынаулар алып килә. Коронавирус безне, иң беренче чиратта, тәртипле булырга өйрәтте. Сәламәтлегеңә игътибарлы булуның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын аңладык. Хәзер диспансеризация дә башкача бара. Кеше анда теләп йөри. Бу – бик яхшы күрсәткеч. Ник дигәндә, диспансеризация вакытында бик күп чирләр башлангыч чорда ук ачыклана. Ә чир никадәр иртәрәк табылса, аны тулысынча җиңү ихтималы да бермә-бер арта. Әйтик, яман шеш беренче-икенче стадиядә чакта ачыкланса, аннан тулысынча котылырга мөмкин. Хәтерләсәгез, иң беренче ковид госпитальләренең берсе бездә ачылган иде. Бүген бездә йөкле хатын-кызлар өчен генә шундый бүлек эшли. Хәзерге вакытта анда коронавирус йоктырган 4 хатын-кыз дәвалана.

:: Булачак әниләр, дигәннән, РКБның перинаталь үзәге дә бүген иң көчле бала табу йортларының берсе санала бит...

– Бездә, дөрестән дә, бала табу өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Перинаталь үзәктә бер көнгә уртача 27ләп бала дөньяга аваз сала. Авыр очраклар да күп. Шуңа күрә перинаталь үзәктә вертолет, реанимобиль, табиблар һәрчак әзер тора. Бездә бик көчле УЗИ аппараты бар. Районда тикшеренгәндә ниндидер сораулар туса, аны тәгаенләп бетерү өчен, йөкле хатын-кызны безгә җибәрәләр. Андый чакта хәлиткеч сүз бездә әйтелә. Быелның 1 гыйнварыннан бездә тагын бер яңалык гамәлгә керде. Бездә генә түгел, бөтен республика күләмендә яңа туган балаларның анализларын Мәскәүдәге генетик үзәккә юллыйбыз. Бу нәселдән күчә торган 46 төрле авыруны вакытында ачыкларга ярдәм итә. Гомумән, федераль үзәкләр белән элемтәдә торабыз. Катлаулы диагнозлы, авыр хәлдәге йөкле хатын-кызларны бала табарга шунда җибәрәбез. Якын арада аналыгында яман шеш табылган бер хатын-кызны шунда озатачакбыз. Безнең өчен һәр гомер кадерле. Һәрбер гомер өчен ахыргача көрәшәбез. Җитлекмичә туган, хәтта авырлыгы 500–600 граммнан артмаган балаларның да гомерен саклап калып, җитлеккәнче үстерәбез. Яңа туган балалар саны кимү бигрәк тә борчуга сала. Мин ДРКБның баш табибы булып эшләгән чорда республикада елына 56 мең чамасы бала туа иде. Хәзер бу сан 38 мең чамасы гына. Кызганыч, соңгы җиде ел эчендә вазгыять шулайрак үзгәрде.

:: Моның төп сәбәбе нидә икән? Ничек уйлыйсыз: балалар күбрәк тусын өчен, ни эшләргә кирәк?

– Миңа калса, бу очракта иң төп проблема – ирләрдә. Балалар күбрәк тусын өчен, иң элек ир-атлар сәламәтлеген кайгыртырга кирәк. Ир-ат организмы авыруларга тизрәк бирешүчән. Яшерен-батырын түгел: без ир балаларның сәламәтлеген мәктәп тәмамлаганда ук югалтабыз. Кыз балалар хатын-кыз табибына даими күренеп тора. Егетләр исә, үсә төшкәч кенә, анда да яшерен, аноним рәвештә, шәхси медицина оешмаларына бара. Шуңа күрә балалар күбрәк тусын дисәк, ир-ат сәламәтлеген мәктәп яшеннән үк кайгырта башларга кирәк.

– Соңгы арада табибларның абруе арттымы, кимедеме? Үз күзәтүләрегездән чыгып, бу уңайдан ни әйтә аласыз?

– Бүген табибларның абруе бик зур. Моңа коронавирус та бик нык этәргеч булды. Аннары табибның абруе үзеннән дә тора. Алар үзләрен һәм хезмәттәшләрен хөрмәт итеп эшли икән, ул җирлектә барлык табибларның да абруе югары булчачак. Киресенчә, белгечләр бер-берсен санламый, үзара аралашып, килешеп эшләми икән, аларның халык арасында да абруе булмаячак.

– Һөнәрегез физик яктан да, рухи яктан да бик авыр. Кайдан көч аласыз?

– Позитив булуым коткара. Бар нәрсәдә яхшылык, һәр әйбернең уңай ягын күрергә тырышам.

Әңгәмәдәш – Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РКБ ЭШЧӘНЛЕГЕ – САННАРДА

➤ Узган ел Республика клиник хастаханәсенә 96 мең кеше мөрәҗәгать иткән, шуларның 54 меңе биредә ятып дәваланган.

➤ Ел дәвамында РКБда барлыгы 30,5 мең операция ясалган. Шуларның 130ы – бөер һәм бавыр күчереп утырту буенча катлаулы операция. Гомумән алганда, соңгы биш елда РКБда ясалган трансплантация саны дүрт тапкыр арткан.

➤ РКБдагы перинаталь үзәктә ел саен 8 меңгә якын бала дөньяга аваз сала. Быел биредә бала тапкан иң яшь әнигә – 14 яшь, иң өлкәненә 56 яшь булган. Үзәкнең реанимация бүлегендә ел саен авырлыгы 1 килодан артмаган 100ләп баланың гомерен саклап калалар.

27 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00, 14.45 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ТРЮКАЧ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль майдан» 16+
17.30 «Сәләт» 6+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 «Машков» 12+
00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Секс при свете» 18+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 О самом главном 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 60 минут 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 Малахов 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.45 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 09.05, 12.45, 14.45, 16.50 Новости
07.05, 09.45, 21.45, 00.45 Все на Матч!
09.10, 10.10, 11.05, 12.10, 14.10 Санный спорт. Кубок России
10.45 Специальный репортаж 12+
11.30 «Вы это видели» 12+
12.50 «Есть тема!»
14.50 «Громко».
15.50 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Динамо» (Махачкала) – «Торпедо»
19.00 «Громко»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Локомотив» (Ярославль)
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
02.00 Акробатический рок-н-ролл. Чемпионат мира 6+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – МБА (Москва) 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 Утро. Самое лучшее 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Место встречи
16.45 За гранью 16+
17.50 ДНК 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «На стороне чувств» 16+
00.00 «МЕДНОЕ СОЛНЦЕ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.25 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.35 «Знахарка» 16+
13.30, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» (2020) 16+
19.00 «ГРЫМЗА» 16+
02.55 «ДОЛГАЯ ДОРОГА» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «СНАЙПЕР-2. ТУНГУС» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ЧЕРНЫЕ БЕРЕТЫ» 16+
12.40, 03.30 «СНАЙПЕРЫ: ЛЮБОВЬ ПОД ПРИЦЕЛОМ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Битва за Днепр» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Шедевры военных музеев» 12+
00.15 «ТЕМНЫЙ ИНСТИНКТ» 16+
03.15 «Оружие Победы» 12+

28 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
18.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Лада» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ТРЮКАЧ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль майдан» 16+
19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+

РОССИЯ 1

09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 О самом главном 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 60 минут 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 Малахов 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.45 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 14.50, 17.00 Новости
07.05, 13.50, 17.05, 20.15, 01.00 Все на Матч!
10.05, 13.30 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игра миллионов» 12+
11.25, 14.55 Футбол. Чемпионат мира (U17)
14.20 «Что за спорт?» 12+
18.00 Футбол. FONBET Кубок России. 1/4 финала. «Балтика» (Калининградская область) – «Локомотив» (Москва)
20.30 Футбол. Лига чемпионов 6+
03.55 Новости 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Заречье-Одинцово» (Московская область) – «Спарта» (Нижний Новгород) 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 Утро. Самое лучшее 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Место встречи
16.45 За гранью 16+
17.50 ДНК 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
01.45 «ПОТЕРЯННЫЕ» 16+
04.10 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.05 «Давай разведёмся!» 16+
08.05 «Тест на отцовство» 16+
10.15, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.25, 00.30 «Порча» 16+
12.30, 01.35 «Знахарка» 16+
13.05, 02.05 «Верну любимого» 16+
13.40, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
13.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.15 «Твой Домашний доктор» 16+
14.30 «И РАСЦВЁЛ ПОДСОЛНУХ…» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ ЗЛА» 16+
02.55 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» (2020) 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05, 12.40, 03.35 «СНАЙПЕРЫ: ЛЮБОВЬ ПОД ПРИЦЕЛОМ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ЮНГА СО ШХУНЫ «КОЛУМБ» 6+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Битва за Днепр» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Шедевры военных музеев» 12+
00.15 «ТЕМНЫЙ ИНСТИНКТ» 16+
03.20 «Оружие Победы» 12+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

САЛКЫНДА ТҮГЕЛ ХИКМӘТ

Цистит – иң киң таралган сидек юлы авыруларының берсе. Ул сидек куыгы лайлалы тышчасының ялкынсынуыннан гыйбарәт. Көннәр суытып, кышкы чорга аяк баскач, аеруча еш очрый ул. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, бүген цистит бала табу яшендәге гүзәл затларның – 10–15 процентында, менопауза чорына кергән хатын-кызларның 20 процентында була.

vk.com

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА әлеге авыру турындагы иң киң таралган уйдырмаларга ачыклык кертте.

1 нче уйдырма. Туңсаң, цистит белән авыру котылгысыз. Бу сүзләрдә өлешчә хаклык бар. Ник дигәндә, туңгач, кешенең иммунитеты начарлана. Шул рәвешле организм чирләргә тизрәк бирешә. Әмма цистит, нигездә, инфекция аркасында пәйда була. Хатын-кызның оча сөяге өлеше үзенчәлекле. Шуңа бәйле рәвештә, сидек куыгына илткән юл да кыскарак. Бу исә бактерияләргә җәнес әгъзаларына туры юл ача.

Үзем сынадым

Петрушка орлыгы коткарды

Елга бер тапкыр булса да циститтан азапланам. Андый чакта хәлне җиңеләйтүче бер ысул таптым. Көненә 10–12 петрушка орлыгы ашап куйсаң, кычыту, кече йомыш белән чыкканда кисеп авырту кебек билгеләрнең эзе дә калмый.

Исемем редакция өчен генә

2 нче уйдырма. Цистит белән гүзәл затлар гына авырый. Нигездә хатын-кыз чире булып саналса да, әлеге чир ир-атларны да аямый. Ул күбрәк иммунитеты какшаган, простатиттан интеккән ир-атлар арасында очрый.

3 нче уйдырма. Циститтан антибиотик кына коткара. Чынлыкта әлеге чирне ничек дәвалыйсын фәкать табиб кына хәл итәргә тиеш. Ул бу очракта иң элек циститның ни сәбәпле пәйда булуын исәпкә алачак. Циститны ялкынсынуга каршы, табигый яки бактериаль чаралар ярдәмендә дә дәвалыйлар. Циститның иң хәтәр чагында гадәттә – антибиотик, хроник булганда составында үләннәр күп булган дарулар эчәләр.

4 нче уйдырма. Циститны халык медицинасы чаралары ярдәмендә дә җиңеп була. Дөрестән дә, цистит белән авырганда андый алымнар да кулланыла. Үләннәрдән ясалган төнәтмә, ванналар аеруча популяр. Әмма алар дәвалау курсына өстәмә рәвештә генә кулланылырга тиеш. Циститны халык медицинасы ярдәмендә җиңеп булмый. Шул ук җылыткыч чаралар да авыруны вакытлыча гына басып тора. Цистит вакытында халык медицинасы белән артык мавыксаң, вируслар корсак куышлыгына кадәр үк таралып, бөер ялкынсынуга (пиелонефрит) китерергә мөмкин.

ЦИСТИТНЫ НИЧЕК БУЛДЫРМАСКА?

✓Калын киенегез, туңудан сакланыгыз.
✓Көненә, ким дигәндә, ике литр чиста су эчегез.
✓Стресстан сакланыгыз. Йокы режимын бозмагыз.
✓Көн дәвамында утырып эшләүчеләргә 5–10 минут ял итеп алуны да гадәткә кертергә кирәк.
✓Дөрес туклану хәерле. Ачы, тозлы, маринадланган, кыздырылган ризыкларны чикләргә киңәш ителә.
✓Шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәп, эчке киемне көн дә алыштырыгыз.
✓Циститтан саклану өчен, кече йомышны сузып йөрмәү, җенси мөнәсәбәтләр вакытында саклану чаралары куллану да мөһим.

5 нче уйдырма. Кайбер ризыклар цистит китереп чыгара ала. Бу фикер фәнни яктан дәлилләнмәгән. Дөрес, кофеин, исерткеч эчемлекләр, ачы ризыклар цистит белән авырган кешенең хәлен авырайта. Әмма алар мөстәкыйль рәвештә чир китереп чыгара алмый.

6 нчы уйдырма. Җенси тормыш белән цистит арасында бернинди бәйләнеш юк. Бу – ялгыш фикер. Әлеге чир җенси юл белән дә күчә ала.

Чәчне ничек киптерергә?

Чәч сәламәт булсын дисәң, биш хатадан сакланырга кирәк! Табиб-трихолог Анастасия Курская шулай дип ышандыра. «Аргументы и факты» басмасына чәчне фен белән киптергәндә истә тотарга кирәкле кагыйдәләр турында сөйләгән ул.

•Арзанлы фен куллану. Феннан бәргән һава ташкыны никадәр көчлерәк булса, чәч тә шулкадәр тизрәк кибәчәк, зыяны да азрак булачак. Арзанлы феннарда исә һава ташкыны бик акрын була, чәчләр югары температурада кибә. Моннан тыш баш тиресен пешерү куркынычы да зур.

pinterest.com

•Чәчне юуга ук киптерергә ярамый. Сөлгегә урап, 5 минут чамасы сабыр итәргә кирәк. Әмма шуннан да озаграк тотарга ярамый. Юкса, чәч үзлегеннән кибеп бетеп, фен аны зарарларга гына мөмкин. Чәчне фен белән 10–30 минуттан да озаграк киптерергә ярамый. Бар да чәчнең озынлыгына, калынлыгына бәйле.

•Күпләр феннан чыккан һава кайнаррак булган саен, чәч тә яхшырак һәм тизрәк кибә, дип саный. Әмма бу – ялгыш фикер. Артык кайнар һава чәч бөртекләрен зарарлый. Шуңа күрә феннан чыккан һава уртача җылылыкта булырга тиеш.

•Чәчләргә зыян килмәсен өчен, фен баштан 15–20 сантиметр ераклыкта булырга тиеш.

•Чәчне фен белән киптерер алдыннан махсус саклагыч спрей да сиптерергә онытмагыз.

Саклап куй!

Ангинадан

ТАМАКНЫ ЧАЙКАУ ӨЧЕН

Чөгендер суы. Моның өчен чөгендерне вак тишекле угычта уып, иң элек суын чыгарырга кирәк. 1 стакан чөгендер суына 1 аш кашыгы серкә өстисе. Шуның белән тамакны көненә 5–6 тапкыр чайкыйсы.

Суган кабыгы төнәтмәсе. 3 чәй кашыгы суган кабыгын 0,5 л суга салып кайнатырга, 4 сәгать төнәткәч, сөзәргә кирәк.

Сарымсак төнәтмәсе. Чистарткан һәм ваклаган 100 г сарымсакка бүлмә температурасындагы 100 мл кайнаган су салып, өстен томалап 5–6 сәгать торгарга, шуннан соң сөзеп, җылымса килеш тамакны чайкарга.

Баллы су. Баллы су белән чайкасаң, тамак бизләренең шеше кими, эренле шешләр бетә.

ЭЧҮ ӨЧЕН

Лимон. Авыруның башлангыч чорында ярты лимонны кабыгы белән бергә ашыкмыйча гына ашарга кирәк. Шуннан соң бер сәгать буена бернәрсә дә ашыйсы, эчәсе түгел. 3 сәгатьтән соң лимонны кабат ашарга була.

Кәрәз. Ашап-эчкәч, авызга бармак очы хәтле генә кәрәзне кабып чәйнәргә кирәк. Моның өчен көненә 5 г кәрәз җитә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ҺӘР БҮЛМӘНЕҢ – ҮЗ ГӨЛЕ

Гөлләрнең кәефкә йогынты ясавына кайберәүләр ышанып та җитмәскә мөмкин. Ләкин биологлар, һәрбер үсемлекнең үзенә бер тәэсире, үзенә бер көче бар, дип ышандыра. Шуңа күрә гөл үстергәндә аның кайда утырачагы шулай ук әһәмияткә ия.

vk.com

Балалар бүлмәсе

Иң якты, иң «шат», бөтен яктан «дөньясы түгәрәк булган» бүлмәгә гөлне матурлыгына карап түгел, ә куркынычсызлыгы һәм файдасыннан чыгып сайларга кирәк.

Лимон агачы. Һаваны сафландырып, микроблардан чистартып тора. Җимеше генә түгел, яфраклары да сихәтле. Цитрусның эфир майлары баланы тынычландыра, йокысын яхшырта. Ә инде җимеше дә пәйда булса…

Каланхоэ. Грипп вирусына каршы тору сәләтенә ия. Көч өсти, йокыдан уяныргa булыша. Шул ук вакытта җете чәчәкләре бүлмәне бизәп тора. Үрчүе дә бала өчен бик кызык. Яфраклары кырыйларында «бәби»ләре урнаша. Вакыты җиткәч, «бәби»ләр туфракка коелып, җиңел генә үсеп чыга.

Аш-су бүлмәсе

Дымлы-парлы, плитәдән эссе чыккан бүлмәдә иң чыдам үсемлекләр генә әйбәт үсә.

Яран. «Әбиләр гөле» кухнягызны ваниль, алма яки роза исләренә күмәчәк (үсемлекнең төренә карап). Тирәюньгә хуш ислар тарату белән бергә, һаваны чистартучы матдәләр дә бүлеп чыгара ул. Әллә ни тәрбия дә, суны еш сибүне дә таләп итми. Шул ук вакытта бүлмәгә үзенә күрә бер нур өсти.

Хлорофитум. Нәзберек түгел, һаваны бик яхшы чистарта, зарарлы матдәләр тәэсирен юкка чыгара. Иң мөһиме – эсседән дә, дымлылык, утәли җилдән дә курыкмый. Яктырак урында яфраклары җетерәк төстә була.

Йокы бүлмәсе

Күзләрне ялыктырмый торган матур савытлы гөлләр сайлагыз. Ләкин алар күп кирәкми.

Алоэ. Томау төшкәндә «ашыгыч ярдәм» генә түгел бу. Белгечләр әйтүенчә, йокы бүлмәсендә алоэ үстерүчеләр хәтта көзен-кышын да сирәк чирли. Үсемлек формальдегидның (ДСП һәм заманча башка материаллардан ясалган җиһаз чыгара торган зарарлы матдә) 90 процентына кадәр үзенә йота, бүлмәдәге әйберләрнең чатыр-чотыр килеп электрлашуын булдырмый.

Фикус. Әлеге зур гөл йортка тынычлык иңдерә. Әйтергә кирәк, караватка якын куюю киңәш ителгән бердәнбер гөл бу. Фикус, токсиннарны йотып, һавага фитонцидлар бүлеп чыгара.

Кунак бүлмәсе

Аны күзгә бәрелеп торган зур гөлләр белән бизәргә мөмкин.

Монстера. Яфраклары ачык уч төбен хәтерләткән бик купшы гөл. Кеше күп җыела торган урыннар өчен генә яратылган диярсең. Тискәре энергияне үзенә суырып, уңай энергия чыгара. Һаваны озонга, кислородка баетып, дымландырып тора.

Сансевиерия (чуртан койрыгы). Электр приборларыннан чыккан зарарлы нурланышны үзенә сендереп, һаваны чистарта.

Укучы киңәше

Иске линолеумны ничек яңартырга?

Аш бүлмәсе һәм коридор идәне өчен бик уңайлы ул. Тик вакытлар узу белән төссезләнеп кала, ярыла башлый. Ләкин аны алыштырырга ашыкмагыз. Аны җайлы гына яңарту ысулы бар. Моның өчен ике әйбер: өслекне чистарту өчен уайт-спирит һәм элпә хасил итүче сыекча – олиф кирәк.

Линолеумны иң элек уайт-спирит белән чистартыгыз. Кипкәч, олиф белән буягыз. 10–15 минуттан соң идәнне киҗе-мамык тукыма кисәге белән сөртеп-ышкып чыгыгыз. Болай эшләгәндә, линолеум шундук яңарып, матураеп китәчәк!

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА.
Казан

Кимерүчеләрдән котылдым

Суыклар җитүгә, кимерүчеләр кыр-бакчалардан җылы өйләргә керү ягын карый. Аларны агулауга караганда, куркытуны кулайрак күрәм.

Шәхсән мин үзем таҗсыз ромашканы (душистая яки зеленая дип атала) иң яхшы, кеше өчен иң зарарсыз куркыту ысулы дип саныйм. Тик аны гадәтие (аптечная) белән бутарга ярамый. Өй, юл кырыйларында үсә ул.

Тычкан-күсеәләр нәкъ менә шушы ромашканың исен өнәми. Җәй көне шуны җыеп, бәйләмнәр ясап киптерәм. Шуннан соң бәйләмнәрне келәткә капчыклар арасына, өйдәге почмакларга куеп чыгам. Кимерүчеләрнең эзе дә калмый!

Сәвия ГАЛИУЛЛИНА.
Балык Бистәсе

Тәмле булсын!

Витаминлы кишер пирогы

Римма ҖАМАЛИЕВА рецепты

Кирәк булачак: 350 грамм кишер (уылган), 280 грамм бодай оны, 320 грамм шикәр комы, 5 йомырка, 240 грамм шикәр пудрасы, 100 грамм әстерхан чикләвеге төше, 1 аш кашыгы әфлисун кабыгы (уылган), 2 чәй кашыгы камыр күперткеч (разрыхлитель), 1 стакан үсемлек мае, 3 аш кашыгы сөт, 1 чәй кашыгы төелгән дарчин (корица), 1 аш кашыгы лимон согы, 2 чеметем ванилин, ярты чәй кашыгы тоз.

Чикләвек төшен ваклыйбыз (бер азын өстен бизәү өчен калдырабыз). Онга камыр күперткеч, тоз һәм дарчин салабыз. Тирәнрәк савытка йомырка белән шикәр комын салып күпертәбез. Шуңа үсемлек мае белән он катнашмасын салабыз. Кишер, әфлисун кабыгы, чикләвек өстибез дә болгатабыз. Камырны табага урнаштырабыз. 180 градуска җылытылган мичтә 45 минут пешерәбез. Аннары табадан алып, суытабыз. Суынгач, өстенә шикәр ширбәте сылыйбыз һәм чикләвек белән бизибез.

Ширбәт ясау өчен, шикәр пудрасына сөт һәм лимон согы салып, яхшылап болгатырга кирәк.

Исеңдә тот!

Кәнфит түгел, кәтлит!

Диетологлар кәефне төшергән салкын чорда кәнфит һәм камыр ризыкларыннан тыелып торырга киңәш итә. Алар әйтүенчә, күңел күтәренкелеге өчен түбәндәге ризыкларга өстенлек бирү әйбәт.

➤**Тавык ите.** Пешерелгән, кыздырылган, кәтлит итеп ясалган булырга мөмкин. Анда бәхет гормоны дофаминны көчәйтеп җибәрүче тирозин матдәсе бар. Менә шул, кәефне яхшыртып, тынычланырга ярдәм итә.

➤**Банан.** B_6 витаминына бай. Ул нерв системасын саклый, арыганлыкны бетерергә ярдәм итә.

➤**Җиләк-җимеш.** Әйтик, әфлисун, мандарин, хөрмәнең җете матур төсе генә дә күңелне күтәреп җибәрә. Аларда биофлавоноид дигән матдә кан әйләнешен яхшырта, тынычландыра.

➤**Майлы балык.** Скумбрия, кызыл балык, селедка һәм тунец кәефсезләнүдән нык ярдәм итә. Алардагы омега-3 баш мие эшчәнлеген яхшырта, организмны неврозлардан саклый.

Белеп тор!

СОГЫ КҮП БУЛСЫН

Лимоннан һәм лаймнан мөмкин кадәр күбрәк сок сыгып алу өчен нишләргә? Иң элек җимешнең өстенә кул белән катырак басып, өстәлдә әле бер, әле икенче ягы белән тәгәрәтергә кирәк. Эчке элпәләрен җимерү өчен шулай эшлисе. Шуннан соң 2–3 минутка кыска дулкынлы мичкә куеп торасы. Шул рәвешле җимеш йомшарып калачак һәм согын, тамчысын да калдырмыйча, җиңел генә сыгып булачак.

ФӘРЕШТӘЛӘР УСАЛ БУЛМЫЙ

Аллаһы Тәгаләнең кеше күзенә күренмәс, әмма адәм баласын туры юлдан йөртүче, Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүдән армас-талмас нурдан яратылган фәрештәләре барлыгы билгеле. Алар нинди? Фәрештәләргә нинди вазыйфа йөкләнгән? Адәм баласын фәрештәгә тиңләргә ярыймы?

«Өметләләр» мәчетеннән Алмаз хәзрәт САФИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне ни өчен яраткан, аларга нинди вазыйфа йөкләнгән?

– Фәрештәләр дип Аллаһы Тәгаләнең нурдан бар иткән иң хәерле җан ияләренә әйтелә. Аларның төп вазыйфалары Аллаһка гыйбадәт кылу һәм Аның әмерләрен үтәүгә бәйле. «Әнбия» сүрәсенең 19–20 аятьләрендә: «Аллаһның фәрештәләре Аңа гыйбадәт кылырга тәкәбберләнмиләр һәм бу эштән туктамыйлар. Алар көне-төне Аллаһны мактыйлар һәм армыйлар», – диелә. Фәрештәләрнең барлыгына ышану Аллаһка иман китерүнең бер шарты булып тора, чөнки алар турында Коръәндә һәм хәдисләрдә хәбәр ителә. Аларның барлыгына ышанмаучы кеше мөселман булмый. Кешеләрдән аермалы буларак, фәрештәләр ашамый, эчми, йокламый, ару-талуны белми, гөнаһлар кылмый, ир белән хатын-кыз җенесенә бүленми. Алар бик тиз хәрәкәт итә һәм бик зур көчкә ияләр. Аларда акыл бар, ләкин гөнаһка этәрүче шәһвәт теләге юк.

:: Нинди фәрештәләр бар?

– Фәрештәләрнең хисабын Аллаһтан башка һичкем белми. Алар күктә бик күп. Шулай ук алар Аллаһы Тәгаләнең боерган хезмәтләрен кылу өчен җиргә дә төшә. Безгә исемнәре билгеле булган фәрештәләр түбәндәгеләр: Җәбраил – пәйгамбәрләргә Аллаһтан хәбәр алып килгән фәрештә. Һәрбер пәйгамбәргә Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен һәм китапларын ул китерде. Коръәнне дә Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) 23 ел дәвамында Җәбраил фәрештә алып килде һәм, укып, аңа мәгънәләрен аңлатты. Микаил – яңгыр, кар яву, җил исү, үсемлекләр үсү кебек табигать күренешләренә җаваплы фәрештә, Исрафил – Кыямәт көне алдыннан Сур быргысына өрүче фәрештә. Ул Сур быргысына ике мәртәбә өрәчәк. Беренче тапкыр барча җан ияләрен һәлак итү, аннары Кыямәт көнендә үлекләрне терелтү өчен. Мәләкүл-мәүт – җаннарны алучы үлем фәрештәсе. Кайбер дини китапларда аның исеме Газраил дип килә. Мөнкир белән Нәкир – кабердә сорау алучы ике фәрештә. Алар үлгән һәр кешедән «Раббың кем?», «Пәйгамбәрең кем?», «Динең нинди иде?» дип сорый. Мәлик – җәһәннәм сакчысы, Ридван – җәннәт сакчысы, Кирамүн – Кәтибүн – кешеләр артыннан гамәлләрне күзәтеп һәм язып баручы ике фәрештә. Кешенең уң ягында булган фәрештә аның изге гамәлләрен һәм әйткән яхшы сүзләрен яза, ә сул яктагысы гөнаһлы гамәлләрне һәм сүзләрне язып бара.

Алардан тыш, Җир йөзендә һәрбер бәндәне зарар һәм зыяннан, афәтләрдән саклап йөрүче сакчы фәрештәләр дә бар.

:: Фәрештәләрнең төс-кыяфәтләре, зурлыгы турында мәгълүмат бармы?

– Коръәндә һәм хәдисләрдә кайбер фәрештәләрнең кыяфәтләре һәм зурлыклары турында хәбәр ителә. Мәсәлән, Җәбраил фәрештәнең кыяфәте турында «Нәҗем» («Йолдыз») сүрәсенең 5–6 нчы аятьләрендә аңлатыла. Аллаһы Тәгалә: «Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) Коръәнне бик тә куәтле, матур кыяфәтле фәрештә өйрәтте», – ди. Моннан тыш Коръәндә фәрештәләрнең канатлы булулары турында хәбәр ителә. Бер хәдистә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) Аллаһның тәхетен күтәреп торучы фәрештәне сыйфатлап: «Миңа Аллаһның тәхетен күтәреп торучы бер фәрештә турында сөйләргә рөхсәт ителде. Аның колагы белән иң өсте арасындагы ераклык җиде йөз еллык юл хәтле», – диде.

:: Кешене фәрештәгә тиңләргә ярыймы? Еш кына: «Син фәрештәдәй матур, син фәрештә кебек», – дип әйтәбез бит.

– Берәр кеше турында мактап сөйләгәндә, анда булган матурлык, рәхимлелек, изгелек кебек күркәм сыйфатларны фәрештә белән чагыштыру рөхсәт ителә. Мәсәлән, «фәлән кеше фәрештәдәй матур», «фәлән кеше фәрештәдәй яхшы иде» дип мактап искә алу ярый, ди ислам галимнәре.

:: Фәрештәне кеше күзе күрергә мөмкинме?

– Фәрештәләрне нурдан яратылган асыл кыяфәтләрендә күреп булмый. Бары тик Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) генә Җәбраил фәрештәне ике тапкыр асыл сурәтендә күрә алды. Фәрештәләр кеше кыяфәтенә кергән очракта гына аларны күз белән күреп була. Бу хакта Коръәндә һәм хәдисләрдә дә әйтелә.

:: Фәрештәләр начар, усал була аламы?

– Юк, чөнки Аллаһы Тәгалә аларны Коръәндә «Әнбия» сүрәсенең 26–27 аятьләрендә мактап: «Фәрештәләр – Аллаһның хөрмәтле коллары. Алар Аны узып бер сүз дә әйтмиләр. Алар Аның әмеренә буйсынып гамәл кыла», – ди.

Ә менә җәһәннәмдә Аллаһның әмерләрен үтәүче зобани фәрештәләр имансыз кешеләргә карата усаллык күрсәтәчәк. Аллаһы Тәгалә «Тәхрим» сүрәсенең 6 нчы аятендә: «Әй, иман китергән кешеләр! Үзегезне һәм гаилә әгъзаларыгызны ягулыгы кешеләр һәм ташлар булган җәһәннәм утыннан саклагыз. Анда Аллаһка каршы килмәүче, Аның әмерләрен үтәүче кырыс, каты газаплаучы, көчле фәрештәләр булачак», – дип кисәтте.

ru.freepik.com

Декабрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Иkende намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Җом	05:31	07:48	13:27	15:16	17:11
2	Шим	05:32	07:49	13:27	15:15	17:10
3	Якш	05:33	07:51	13:26	15:14	17:10
4	Дүш	05:34	07:52	13:25	15:13	17:09
5	Сиш	05:36	07:54	13:25	15:13	17:09
6	Чәрш	05:37	07:55	13:24	15:12	17:08
7	Пәнҗ	05:38	07:57	13:24	15:12	17:08
8	Җом	05:39	07:58	13:24	15:11	17:08
9	Шим	05:40	07:59	13:23	15:11	17:08
10	Якш	05:41	08:01	13:23	15:10	17:08
11	Дүш	05:42	08:02	13:23	15:10	17:08
12	Сиш	05:43	08:03	13:23	15:10	17:08
13	Чәрш	05:44	08:04	13:23	15:10	17:08
14	Пәнҗ	05:45	08:05	13:23	15:10	17:08
15	Җом	05:46	08:06	13:23	15:10	17:08
16	Шим	05:46	08:07	13:23	15:10	17:08
17	Якш	05:47	08:08	13:23	15:10	17:08
18	Дүш	05:48	08:09	13:23	15:10	17:09
19	Сиш	05:48	08:09	13:23	15:10	17:09
20	Чәрш	05:49	08:10	13:24	15:11	17:09
21	Пәнҗ	05:50	08:11	13:24	15:11	17:10
22	Җом	05:50	08:11	13:25	15:12	17:10
23	Шим	05:51	08:12	13:25	15:12	17:11
24	Якш	05:51	08:12	13:26	15:13	17:11
25	Дүш	05:51	08:12	13:27	15:13	17:12
26	Сиш	05:52	08:13	13:27	15:14	17:13
27	Чәрш	05:52	08:13	13:28	15:15	17:13
28	Пәнҗ	05:52	08:13	13:29	15:16	17:14
29	Җом	05:52	08:13	13:30	15:17	17:15
30	Шим	05:53	08:13	13:31	15:18	17:16
31	Якш	05:53	08:13	13:32	15:19	17:17

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йәгез, бер дога!

БАШ АВЫРТКАНДА УКЫЛА

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бисмилләһил-кәриим. Үә әгуузү билләһилгәзыыйм мин шәрри кулли гиркый нәәри үә мин шәрри хәррин-нәәр».

Мәгънәсе: «Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Кәрим булган Аллаһ исеме белән. Һәртөрле авыруның зыяныннан һәм җәһәннәм уты начарлыгыннан бөек Аллаһыга сыенам».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

БЕР ДУЛКЫНДА

«ШАЯН ТВ» БАЛАЛАР ТЕЛЕКАНАЛЫНА 5 ЯШЬ ТУЛДЫ!

«ШАЯН ТВ» кара – булырсың шәп бала!» Бу сүзләрне инде биш ел дәвамында һәр татар гаиләсендә ишетергә мөмкин. 2018 елның 12 ноябрендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән тәүге тапкыр эфирга чыккан әлеге канал балалар белән бер дулкында яши. Тәүлек әйләнәсе эшләүче беренче татар балалар телеканалына кунакка барып, нәни хезмәттәшләребезнең нинди шөгыльләнүләрен күреп кайттык.

...Коллегаларыбызның һәр минуты санаулы. Мәктәптәге дәресләрдән бушауга, студиягә йөгерәләр. Тапшыру, монтаж, стенд-ап, дубляж ише сүзләр аларга ят түгел. Үзләре уйлап та таба, сюжет төшерергә дә чаба, монтаж эшендә дә, тавышландыруда да катнаша. Кыскасы, «ШАЯН» балаларның энергиясеннән кайнап тора! Каналдагы тормыш үзләренә ошыймы соң? «Йолдыз» чирен эләктермәгәннәрме әле? Үзләреннән сораштык.

«ШАЯН» – САННАРДА

- Телеканал штатында 70 кеше. Бүген телеканалда 100гә якын алып баручы бала һәм телевизион блогерлар эшли.
- Дубляж бүлеге 5 ел эчендә 13000 мультфильм, сериал, төрле тапшырулар тәрҗемә итте. 3 мең сәгатьлек архив тупланды.
- «ВКонтакте»та – 10 меңнән артык язылучы, «ТикТок»та – 87,5 меңнән артык язылучы, «YouTube»та – 15 мең язылучы.

Аяз ӘГЪЛИУЛЛИН:
– Мин «ШАЯН»га 10 яшемдә килдем. Беренче тапшыруымны да хәтерлим. «Шаян балалар»да роботлар турында сөйләгән идем. Беренче тапшырудан соң кабат чакырдылар. Шуннан китте инде. Кабат-кабат чакыра башладылар. Безнең студиябез шундый зур һәм мобиль. Һәрбер эштә үзебез дә катнашабыз. Мәктәптәге укытучыларыбызга да рәхмәт: безнең тапшыру төшерәсе булса, дәресләрдән иртәрәк китәргә рөхсәт итәләр. Безнең редакторларыбыз безнең теләкләрне исәпкә алып эшли. Безнең тәкъдимнәрне, фикерләрне сорап торалар. Каналда нәрсә күрәсе килә, шуларны әйтәбез. «ШАЯН»да хезмәт хакы да алабыз. Иң беренче хезмәт хакымны әнигә алып кайтып биргән идем. Шунысы да истә: съемка вакытында тагын да матур булыр өчен, ул акчага кием алган идек.

Мәрьям ҖӘППАРОВА:
– «ШАЯН ТВ» каналы барлыкка килгәндә, миңа 7 яшь иде. Беренче сыйныфка барган чагым. Татарча канал барлыкка килү минем өчен зур бәйрәм булды! «ШАЯН»да башта әкиятләр сөйләдем, соңрак «Шаян география» тапшыруына алып баручы итеп чакырдылар. Хәзергә кадәр шул тапшыруны алып барам. «Мин сине бу тапшыруда күргән идем бит әле, син «Шаян»нан бит әле», – дип сораштыргалыйлар. Әлбәттә, бу вакытта җаваплылык та тоясың. Миңа калса, бу – каналны популярлаштыру ысулы да. «Шаян» белән кызыксыну туа да, каналны карыйсылары килә, тапшыруга әзәрү юлларын эзлиләр. Хәтта татар телен белмәгән балалар да: «Өйрәнәм! Төшерегез генә мине!» – ди.

Җәмил ХӘБИБРАХМАНОВ:
– Мин дә каналга 10 яшьтә килдем. Шулай ук кастинг аша уздым. Җырларга яратам. Шуңа күрә «Сәйлән» конкурсында да катнаштым. «ШАЯН ТВ»да эшлисеңме? Безнең сине күргән бар!» – дип әйтәләр, танныйлар. Андый чакта бик рәхәт инде.

Әнвәр ХӘЕРТДИНОВ:
– Каналга килеп эләгүем бик кызык булды. Авылга кайтып барганда, радиодан белдерү ишеттек. «ШАЯН»га эшчеләр кирәк! Без алып баручы балалар җыялар дип уйладык. Әмма алар оператор, монтажер кебек эшчеләр эзләгән икән. Ләкин мине кире какмадылар. Әниемә яздылар да беренче съемкага чакырдылар. Бер айдан соң алып баручы буларак эшкә алдылар. Үскәч, «ШАЯН ТВ» каналында «Яшьләр тукталышы» тапшыруын алып барырга теләр идем.

Зәйнәп ХӨСНУЛЛИНА:
– Мин телеканалга күпкә соңрак килеп кушылдым. Ул вакытта миңа 11 яшь иде. Карантин чоры иде бу. Тапшыруларны да өйдә яздыра идек. «Шома бас», «Тәртипле бул!» тапшыруларында эшлим. Блогинг белән мавыгам.

«ШАЯН» УҢЫШЛАРЫ

- ★«ШАЯН ТВ» каналында чыгучы «Күчтәнәч» тапшыруы – «ТЭФИ – 2009» Бөтенроссия телевизион бәйгесе җиңүчесе.
- ★2019 елның 30 августында «ШАЯН ТВ» каналы «Карусель» телеканалы үткәргән «Главные герои» милли балалар бәйгесендә «Ел ачышы» номинациясендә җиңүче булды.
- ★2021 елда телеканал «Многоликая Россия 2021» XIII Бөтенроссия журналистлар конкурсында «Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-яшүсмерләр өчен белем бирү проектлары» номинациясендә 1 нче урын алды.
- ★«ШАЯН ТВ» каналы «Алтын каләм – Золотое перо» XXVII Республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивалендә 3 нче урын алды.
- ★«Кечкенә әкиятләр» тапшыруы алып баручысы Ләйлә Таишева «ТЭФИ-KIDS 2022» премиясендә «Иң яхшы алып баручы» номинациясендә финалист булды.
- ★2023 елда «ШАЯН ТВ» Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты булды.
- ★«ШАЯН ТВ» каналы «Балалар өчен иң яхшы телеканал» номинациясендә Россиянең телевизион «ТЭФИ-KIDS 2023» премиясе финалына чыкты.

Рамилә СӘХАБЕТДИНОВА, «ШАЯН ТВ» башкарма директоры, баш мөхәррир:
– «ШАЯН ТВ»да балалар хуҗа. Безнең балалар алар үзләре текст та яза, тәрҗемә дә итә, тавышландыра да. Без аларны төрле яктан үстерәбез. Менә дигән татар журналистларын тәрбиялибез! Безгә – биш яшь. Бу вакыт бик тиз узып китте. Без шушы вакыт дәвамында бик матур эшчәнлек күрсәттек. Биш ел канал балалар иҗатын таныту буенча даими эш алып бара, бәйге һәм фестивальләр оештыра, татар дөньясына берсеннән-берсе шәп һәм файдалы проектлар тәкъдим итә. Безнең проектлар милли мәгариф өчен дә бик файдалы. Безнең каналда – татар мохите, татар рухы. «ШАЯН» магнит кебек, аңа тартылалар.

Роза ӘДИЯТУЛЛИНА, «ШАЯН ТВ» каналының дубляж студиясе җитәкчесе:
– «ШАЯН» – остазлык мәктәбе. Бу татар элитасын тәрбияли торган татар мохите булган мәйданчыкларның берсе. Безгә килгән балаларның елдан-ел осталыклары да арта, телләре дә шомара. Әтиәниләргә дә рәхмәт. Башта бер балаларын китерәләр, аннары бәләкәйләрен җәлеп итәләр. Шулай итеп, гаиләләре белән бездә эшләүчеләр бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

29 ноябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ һӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «ТРЮКАЧ» 16+
01.15 «Кәмит Җәмит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
09.30, 04.20 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.30. 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ике аккош» 12+
15.25. 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
03.30 «Нечкә билле Зиләйлүкнең җырлары» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 О самом главном 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 60 минут 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 Малахов 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.45 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Голевая неделя. РФ» 6+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 20.15, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игра миллионов» 12+
11.25 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
13.00 «Есть тема!»
14.20 «Вид сверху» 12+
15.45 Футбол. FONBET Кубок России
20.30 Футбол. Лига чемпионов
03.55 Новости 0+
04.00 «Что за спорт?» 12+
04.30 Санный спорт. Кубок России

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 Утро. Самое лучшее 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Место встречи
16.45 За гранью 16+
17.50 ДНК 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
01.55 «ПОТЕРЯННЫЕ» 16+
04.20 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПАВЛИН, ИЛИ ТРЕУГОЛЬНИК В КВАДРАТЕ» 16+
19.00 «ДВОЙНАЯ ПЕТЛЯ» 16+
02.50 И РАСЦВЁЛ ПОДСОЛНУХ... 16+
06.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СНАЙПЕРЫ: ЛЮБОВЬ ПОД ПРИЦЕЛОМ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «СЛУЧАЙ В КВАДРАТЕ 36-80» 16+
12.40, 03.25 «ЖУКОВ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Битва за Днепр» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
02.30 «Неизвестная война. Великая Отечественная» 16+

30 ноябрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «МӘХӘББӘТ һӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Классный час» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15 «Точка опоры» 16+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Автомобилист» 6+. По окончании – «Погружение на 100» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 16+
00.00 «ТРЮКАЧ» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Азбука долголетия» 16+
01.40 «Таяну ноктасы» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 23.10, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00 «Туган авылым» 12+
10.30. 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
18.20 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
19.15, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» 16+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
03.30 «Сагындым... Бик сагындым сине, Туган ил!» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 О самом главном 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 60 минут 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 Малахов 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.45 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.00 Новости
07.05, 14.55, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игра миллионов» 12+
11.25, 17.05 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
13.00 «Есть тема!»
14.20 «Большой хоккей» 12+
15.45 Смешанные единоборства. One FC
18.15 Футбол. Лига конференций
20.30 Футбол. Лига Европы 6+
03.55 Новости 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Белогорье» (Белгород) 6+

НТВ

05.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 Утро. Самое лучшее 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Место встречи
16.45 За гранью 16+
17.50 ДНК 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
00.55 Поздняков 16+
01.10 Мы и наука. Наука и мы 12+
02.05 «ПОТЕРЯННЫЕ» 16+
03.40 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.35 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.45 «Порча» 16+
12.55, 01.45 «Знахарка» 16+
13.30, 02.10 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ВЕРЬ СВОЕМУ МУЖУ» 16+
19.00 «ИДЕАЛИСТКА» 16+
03.05 «6 кадров» 16+
03.15 «ПАВЛИН, ИЛИ ТРЕУГОЛЬНИК В КВАДРАТЕ» 16+

ЗВЕЗДА

05.05, 12.40, 04.00 «ЖУКОВ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ» 12+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Битва за Днепр» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
03.15 «Звездные войны Владимира Челомея» 12+

1 декабрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45, 01.10 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Наши герои» 16+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «ВОЛГА-ВОЛГА» 0+
23.45 «СВАДЕБНЫЙ ПОДАРОК» 12+
01.35 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.50 «Өмет йолдызы» 16+
03.25 «Җырлыйк әле!» 12+
04.20 «Әдәби хәзинә» 16+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 01.50 «Заман көзгесе» 6+
10.30. 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 03.30 «Исламия... тормыш үзе язган рольда...» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.10, 22.15, 02.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
01.05 «Ике аккош» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Фантастика» 12+
23.40 «Матадор» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман вещества» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
04.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
05.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 О самом главном 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 60 минут 12+
14.55 Судьба человека 12+
16.30 Прямой эфир 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 6+
00.25 Шоу Большой Страны 12+
01.30 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 08.30, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 19.30, 22.10, 00.45 Все на Матч!
08.35, 11.50 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
10.20, 13.10 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России
15.30 Смешанные единоборства. One FC
19.45 Футбол. Winline Новая игра
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 «РецепТура» 6+
02.00 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига 6+
03.35 Специальный репортаж 12+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Уралмаш» – «Зенит» 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 Утро. Самое лучшее 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25 Мои университеты. Будущее за настоящим 6+
09.25 «ПЁС» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 Место встречи
16.50 За гранью 16+
17.55 Жди меня 12+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
00.00 Своя правда 16+
01.50 Квартирный вопрос 0+
02.40 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.05 «Давай разведёмся!» 16+
08.05, 03.00 «Тест на отцовство» 16+
10.15, 23.35 «Понять. Простить» 16+
11.20, 00.45 «Порча» 16+
12.30, 01.45 «Знахарка» 16+
13.05, 02.10 «Верну любимого» 16+
13.40, 02.35 «Голоса ушедших душ» 16+
14.15 «Скажи, подруга» 16+
14.30 «ЗАВТРА Я ТЕБЯ РАЗЛЮБЛЮ» 16+
19.00 «РОДНЫЕ И БЛИЗКИЕ» 16+
23.20 «Уют за 15 минут» 16+
04.40 «ВЕРЬ СВОЕМУ МУЖУ» 16+

ЗВЕЗДА

05.05, 12.40 «ЖУКОВ» 16+
08.10 «СТРЕЛЫ РОБИН ГУДА» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
10.25 «РЫСЬ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.05 «Кремль-9» 12+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «ДРУЖБА ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 16+
02.25 «ПРАВО НА ВЫСТРЕЛ» 12+

2 декабрь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 Гала-концерт фестиваля «Наше время – Безнең заман» 6+
16.30 «Халкым минем...» 12+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 6+
17.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «ЖЕНИХ НАПРОКАТ» 16+
23.50 «ПРОЩАЙТЕ, ФАРАОНЫ!» 12+
01.10 «Музыкальный майдан» 16+
01.35 «Бар ул бәхет, бар!» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 Х.Вахит. «Кияүләр». Әтнә татар дәүләт драма театры спектакле 16+
17.15 «Калеб» 6+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Бир кулыңны» 16+
21.50 Т.Миңнуллин. «Хушыгыз!» Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
00.10 «Синең көзләр» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+
13.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
14.35 «КРАЙ» 16+
17.00 «Я люблю мою страну» 0+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Михаил Задорнов: вся жизнь» 16+
19.15 «Эксклюзив» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.20 «ФАВОРИТКА» 18+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
04.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
05.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России. Суббота
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 По секрету всему свету
09.00 Формула еды 12+
09.25 Пятеро на одного
10.10 Сто к одному
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 Доктор Мясников 12+
14.50 «Парад юмора» 16+
17.50 Привет, Андрей! 12+
21.00 «ЭТО ЖИЗНЬ» 16+
00.35 «НЕОТПРАВЛЕННОЕ ПИСЬМО» 12+
04.15 «ТОЛЬКО ТЫ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Что за спорт?» 12+
06.30 «Третий тайм» 12+
07.00 Новости
07.05, 17.00, 21.30, 00.45 Все на Матч!
08.55 «Команда МАТЧ» 0+
09.15 «Небесная грация» 0+
09.35, 12.50 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
10.50 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России
13.40 Биатлон с Дм. Губерниевым
14.10 Теннис. Международный турнир «Кубок Северной Пальмиры»
15.15 Футбол. Чемпионат мира (U17)
17.25 Футбол. Чемпионат Германии
19.25 Футбол. МИР РПЛ. «Пари НН» – «Урал»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
02.00 «Вы это видели» 12+
03.00 Смешанные единоборства. UFC

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
07.30 Смотр 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 Поедем, поедим! 16+
09.20 Едим дома 0+
10.20 Главная дорога 16+
11.00 Живая еда 12+
12.00 Квартирный вопрос 0+
13.10 Попутчик 16+
14.20 Игры разумов 0+
15.00 Своя игра 0+
16.20 ЧП. Расследование 16+
17.00 Секрет на миллион 16+
19.00 Центральное телевидение
20.20 Суперстар! 16+
23.35 Ты не поверишь! 16+
00.35 Международная пилорама 18+
01.15 Уроки русского 12+
01.45 Дачный ответ 0+
02.40 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.55 «ОСТРОВА» 16+
09.55 «Пять ужинов» 16+
10.10 «АТЕЛЬЕ СЧАСТЬЯ» 16+
14.40 «СОЛНЦЕ, МОРЕ И ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.45 «ОДНОКЛАССНИЦЫ» 16+
00.55 ДОЛГАЯ ДОРОГА 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.30 «ЗАВТРА Я ТЕБЯ РАЗЛЮБЛЮ»

ЗВЕЗДА

05.40 «ЖУКОВ» 16+
07.45, 08.15 «ЮНГА СО ШХУНЫ «КОЛУМБ» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.35, 00.45 «ЗЕМЛЯ САННИКОВА» 12+
11.40 «Мужики» 16+
12.10 «СССР. Знак качества» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров» 16+
14.30 «Легенды науки» 12+
15.20 «Главный день» 16+
16.10 «Время героев» 16+
16.35 «Воины Субэдэя» 16+
16.50 «МОРСКОЙ ХАРАКТЕР» 12+
19.20 «Галерея Звезд» 12+
21.00 «ОДИН ШАНС ИЗ ТЫСЯЧИ» 12+
22.50 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
02.15 «СТРЕЛЫ РОБИН ГУДА» 12+
03.35 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
04.55 «Хроника Победы» 16+

3 декабрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 21.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Дуслык илендә» 12+
10.35 «Туган авылым» 12+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Видеоспорт» 16+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.45 «Наша Республика – наше дело» 16+
14.45 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.45 «Ком сәгате» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Нефтехимик» 6+
19.30, 22.30 «Семь дней» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.30 «ОБЛАСТИ ТЬМЫ» 16+
01.15 «ГЕНЕРАЛЬНАЯ УБОРКА» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 Р.Харис. «Сәйдәш яры» 12+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00, 03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» 16+
14.20 «Синең өчен сөюләрем» 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
17.15, 05.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 И.Мәхмутова. «Син бит минем бергенәм». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
15.00 «Правдивая история. Тегеран-43» 12+
17.05 Специальный репортаж 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Перепой звезду» 12+
21.00 «Время»
23.00 «Что? Где? Когда?» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+
02.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

06.15, 01.30 «ТЫ БУДЕШЬ МОЕЙ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 Когда все дома
09.25 Утренняя почта
10.10 Сто к одному
11.00 Вести
12.00 Большие перемены 6+
13.00 «ВСТРЕЧНАЯ ПОЛОСА» 12+
17.00 Песни от всей души 12+
18.00 «Синяя Птица»
19.00 Песни от всей души 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC
08.45, 11.10 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
09.50, 12.20 Лыжные гонки. Альфа-Банк Кубок России
13.35, 15.15, 18.45, 00.45 Все на Матч!
14.00 Теннис. Международный турнир «Кубок Северной Пальмиры»
15.55, 19.20 Новости
16.00 Футбол. МИР РПЛ. «Локомотив» – «Зенит»
19.25 Футбол. Чемпионат Германии
21.30 После футбола с Георгием Черданцевым
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.55 Волейбол. Кубок России. Мужчины. 1/2 финала. «Динамо» – «Зенит» 6+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» – УНИКС 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.35 Центральное телевидение 16+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 У нас выигрывают! 12+
10.20 Первая передача 16+
11.00 Чудо техники 12+
12.00 Дачный ответ 0+
13.00 НашПотребНадзор 16+
14.05 Однажды... 16+
15.00 Своя игра 0+
16.20 Человек в праве 16+
17.00 Следствие вели... 16+
18.00 Новые русские сенсации 16+
19.00 Итоги недели
20.20 «Шоу Аватар» 12+
23.10 Звезды сошлись 16+
00.40 Квартирник НТВ у Маргулиса. Группа «25/17» 16+
02.00 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.45 ОДНОКЛАССНИЦЫ 16+
09.55 «Уют за 15 минут» 16+
10.10 «ЛЮБОВЬ ВО ВСЁМ ВИНОВАТА» 16+
14.45 «КАЧЕЛИ ПОД КУПОЛОМ» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.50 «Твой Домашний доктор» 16+
23.05 ОСТРОВА 16+
01.10 «Москвички» 16+
06.05 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «МОРСКОЙ ХАРАКТЕР» 12+
07.15 «ОДИН ШАНС ИЗ ТЫСЯЧИ» 12+
09.00 Новости дня 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «Специальный репортаж. Что русскому смешно...» 16+
13.55 «СНЕГ И ПЕПЕЛ» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «Люди Донбасса» 16+
00.10 «ПРИКАЗ: ОГОНЬ НЕ ОТКРЫВАТЬ» 12+
01.50 «ПРИКАЗ: ПЕРЕЙТИ ГРАНИЦУ» 12+
03.20 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
04.55 «Из всех орудий» 16+

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, I чакырылыш (1995-1999), II (1999-2004), IV (2009-2014), V (2014-2019), VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Татарстан агросәнәгать комплексы лидерларыннан берсе, талантлы җитәкче, республиканың экологик законнарын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән абруйлы депутат арабыздан мәңгегә китте.
Илшат Газыйм улы Ганиевнең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улы
вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Илшат Газыйм улының бакыйлыкка күчүе – безнең өчен зур югалту. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм агросәнәгать хезмәткәрләре профсоюз оешмасы «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улының
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, аның туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улы
кинәт вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективы, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты
ГАНИЕВ
Илшат Газыйм улы
вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе
ХОМЯКОВА
Әминә Ягъфәр кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлек итүне координацияләү идарәсе контрольлек бүлеге баш киңәшчесе Фәйзуллина Диана Геннадиевнаның авыр кайгысын уртаклаша.

КАРАКҮЛ ГАЗ КӨТӘ

Нурлат районының Каракүл авылында яшәүчеләр өйләрен җылыткан өчен айга 12 мең сум акча түләргә мәҗбүр. Анда кышны нибары 20ләп кеше чыга. Күбесе – әби-бабайлар. Иң өлкәненә – 106 яшь. Каракүлләр гомер буе йортларына газ керер дип өметләнеп яши. Капка төпләрендә – сиртмәле коелар. Кечкенә авылның өметләре акланырмы, әллә утын әзерләүне һаман дәвам итәсеме? «ВТ» журналисты, Каракүл урамын әйләнеп, халыкның яшәеше белән кызыксынып кайтты.

Чыра һәм ут

Каракүлдә 36 йорт бар, пропискада 28 кеше тора. Анда балалар тавышын бары җәй көне генә ишетәләр. Өлкәннәр өчен бу күренеш бигрәк тансык. Мәктәп, клуб, кибет, фермаларын да сагынып сөйләргә генә калган. Газ һәм су кермәгән, карт-коры яши дигәч тә, йортлары искереп беткән, тормыштан бөтенләй артта калганнар дип уйламагыз тагын. Юк, алай түгел. Урман кочагында урнашкан Каракүлдән ниндидер яктылык бөркелә. Авыл урамы буйлап яшь чыршылар күтәрелеп килә әнә. Безнең игътибарны бигрәк тә сиртмәле коелар (авылда аны колгалы дип атыйлар. – **Авт.**) җәлеп итте. Утыз коеның алтысы шундый икән. Мәчет морҗасыннан күтәрелгән төтен – авылда тормыш та, дин дә бар әле дигәнгә ишарә. Гыйбадәт кылырга нибары өч карт кына йөрсә, гаетләргә барысы да җыела икән. Без мәчеткә кергәндә, Әнвәр хәзрәт Шәраповның чыра телеп, мичкә ягышы иде. Учак дөрләгәндә, без хәзрәт белән авылның үткәне, бүгенгесе турында сөйләштек. Авылда мәчет булу – үзе бер сөенеч.

– «Коммунизмга юл» колхозында умарталык өе бар иде. Колхоз таркалгач, аның кирәге калмады. Ул чакта бездә мәчет юк иде әле. Җомга намазын бер йортка җыелып укыдык. Район башлыгына барып, теге умарталык өен алып кайтырга рөхсәт сорадым. Каршы килмәде. Иң беренче булып Минсалих абый Минһаҗев 17 мең сум акча китерде. Халыктан җыелган сәдака акчасына яңа бура бурап, янкорма ясаттык. Шулай итеп, мәчетле булдык, – дип сөйләде 77 яшьлек хәзрәт.

Бай колхоз

Ике ел элек авыл халкы Каракүлнең 100 еллыгын бәйрәм иткән. Ә аның барлыкка килү тарихы болайрак. Бирегә Бикүле авылыннан 19 гаилә күченеп килгән. Аннары йорт саны 32гә җитә. Ярышып эшләр өчен ике бригада төзиләр. Әгәр 15 минут соңга калсаң, «Бүген сиңа эш юк», – дип кире борганнар. Күмәкләшү чорында барысы да ат, терлекләре белән колхозга кергән. Утызынчы елларда игенчелектәге уңышы өчен «Төбәк» колхозы и күләмендә көмеш медаль белән бүләкләнә. Сугыш вакытында умарта тотканнар, янут (енот) үрчеткәннәр. 1952 елны авылда такта ярдыру цехы эшли башлый. Бик бай колхоз булган, кыскасы.

– Заманында «Полуторка»лар, пар машинасы бик сирәк колхозларда гына була иде. Пар машинасының көпчәкләре җиргә күмелгән иде. 500 литрлы мичкәне су белән тутыралар. Мичкә ягып торгач, су парга әйләнә. Утын күп кирәк булгач, аннары дизель моторы белән эшләде ул. Ярты район такта ярдырырга килә иде. Өйләренә төшке ашка кайткан эшчеләр, «паровоз» кычкыртуга, эшкә чаба иде. Мин армиядә чакта аны металлга тапшырганнар, – ди Әнвәр хәзрәт үз заманының казанышы турында.

Авыллар нигә таралган? Әнвәр абый моның сәбәпләрен колхозларны эрелэтүдән күрә. Шуның нәтиҗәсендә күршедәге Прогресс, Маеровка, Хирла кебек авыллар юкка чыккан.

– Балакай, авыл бетә икән, шәһәр дә бетә дигән сүз. Калага халыкны авыл бирә бит. Мин армиядән кайтканда, авылда 200дән артык кеше бар иде. Бүген исә кышка 20 кеше кала. Йортларның кайсында – бер, кайсында – ике кеше. Парлылар да бар. Башкалар язын кошлар кайткан кебек туган нигезенә ашкына. Җәен Авыл көне үткәрәбез. Газ булса, әби-бабайлар кышка балаларына китмәс иде. Утын мәсьәләсе җиңел түгел. Өйне җылытырга 3–4 машина утын кирәк. Халык кайчан да булса газ керер дип өметләнә, – ди хәзрәт.

Кесәгә суга

Асия әби Нигъмәтуллина ире Сәлим бабай белән гомер кичерә. Икесенең дә тугызынчы дистәне ваклап ятышлары. 87 яшьлек әбекәй дә газсыз тормыштан зарланып алды. Өйне электр белән җылыту шактый кыйммәткә төшә. Чыгымнары – пенсиясенең яртысы кадәр.

– Узган ел кышын электрга 4 ай буе 12шәр мең түләдек. Пенсиям – 22 мең сум. Барының бәрәкәте булсын, кызым. Утынны сатып алабыз. Бик салкыннарда гына ягабыз. Мичне сүттермәдем. Үзара салым акчасын да түлибез. Тегеннән артып кайта бит ул. Ул акчага урамга юл салдылар. Файдасы бар, шуңа күрә бирәбез. Ике кызым да Чаллыда яши. Улым 32 яшендә үлде. Балалар, шәһәргә алып китәбез, диләр. Әмма туган нигездән читкә китәсе килми шул, – ди ул.

Моңа кадәр терлек, кош-корт асрап көн күргән алар. Көчләре беткәч, барысын да бетергәннәр. «Абзарга чыгып йөрергә рәт юк», – диләр. Тик Сәлим бабай мәчеткә ике таякка таянып булса да йөри әле. Кызу-кызу атлап кайтып килә иде үзе. Суны да коедан ул ташый.

Зөлфия Хәлиуллина

Коелар илендә

Кое, димәктән, моңа кадәр колгалы коены бары Буа районының Аккүл авылында гына күргән идек. Анда да кеше аз калган инде. Каракүлдә исә колгалы алты кое бар. Игътибар итсәгез, ике авылның да исеме күлгә бәйле. Бер коены аеруча үз итәләр. Суы тәмле дип, күп кеше шунда йөри.

– Аптырамагыз, андый коелар элек күрше авылларда да бар иде. Хәзер калмады инде. Күбесенең өйләренә су керде бит. Безнеке – капка төбендә. Колгалы коены һәркем үзе казытты. Аннан су алу күпкә җиңелрәк. Су өйгә керсә дә, бу коеларны сүттермәс идек. Бер истәлек бит ул. Элек картлар ничек яшәгән, без шул тәртипне үтәргә тырыштык, – диде бүген инде үзләренең дә чәчләренә чал кергән өлкәннәр.

Дәваларга белгеч бар

Кечкенә генә авыл булса да, шәфкать туташы да бар биредә. Тәнзилә Кыямова Кәкре Таудан килеп эшләп йөри. Ике авылга хезмәт күрсәтә ул.

– Штат бервакытта да кыскартылмады. 22 ел эшләгәч, берничә ел туктап торган идем. Аннары тагын әйләнеп кайттым. Җәйге юлдан – 6, кышын Бикүле аша 16 чакрым үтәргә туры килә, – ди Тәнзилә Кыямова.

Өлкәннәрнең хәлләрен белешергә өйләренә дә баргалый, дарулар да илтә. 106 яшьлек Миннегамбәр әбигә аерым игътибар. «Кызы бик яхшы карый аны», – ди шәфкать туташы.

Өмет бармы?

Авылдагы өлкәннәрдән, газны авылга 2024 елда кертәләр, дигән сүзне ишеттек. Киләчәккә планнар хакында район башлыгы урынбасары Линар Мәннәповтан сораштык.

– Авыл халкы әлеге мәсьәлә буенча безгә күптән мөрәҗәгать итә. Каракүлгә газ кертү буенча проект эшләре башланды. Үзебез дә сөендек моңа. Ул 2024 елда әзерләнеп бетәчәк. Проект инде ул – эшнең яртысы дигән сүз. Аннан соң «Татмежрегионгаз» авылны зәңгәр ягулыкка тоташтырачак, – дип өметләндерде Линар Мәннәпов.

Сәрия МИФТАХОВА

УКЫМАСКА ТҮГЕЛ УКЫРГА

ӨТЕР КАЙСЫ УРЫНДА?

Бар дөнья – уч төбендә. Туры мәгънәсендә. Мәгълүматка ия булуның иң җиңел ысуллары бар хәзер кешедә. Әмма сайлый беләбезме соң? Ни өчен кеше уйларга теләми? Баш миенең кирәксә-кирәкмәсә дә бик күп күләмдә мәгълүмат «ашавы» нәрсәсе белән куркыныч? Уйлануларыбыз шул хакта булыр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Төпсез диңгез

Казанда техниканы арендага бирү оешмасында җитәкче ярдәмчесе булып эшләүче Алисә Закирова бернинди дә иҗтимагый-сәяси төрдәге мәгълүмат каналларына язылмаган. Андый яңалыкларны махсус эзләп тә утырмый. Социаль челтәрләрендәге чатлары да бары тик дус-иш һәм эш буенча аралашулар өчен генә.

– Ул-бу булса, бу хакта хәбәрне дусларым җибәрә. Йә эштәгеләрдән ишетәм. Хәзерге заманда нәрсәне дә булса белмичә калу мөмкин түгел. Урамда булса да, ишетәсең. Бөтен нәрсәне белергә омтылмыйм да. Телевизор карамыйм, социаль челтәрләрдә дә яңа законнар, криминал, артистлар тормышына бәйле хәбәрләр укымыйм. Үземнең кызыксынуларыма бәйле каналларга, төркемнәргә язылдым. Шул җитә. Эштән арып кайткач, шуларны бер күз йөртеп чыксам, күңел була, – ди ул. – Туганнар, әти-әниләр кайчагында төрле мәгълүмат чараларынан күреп, берәр нинди хәбәр җибәрә. Алар аның баш исеменә генә алдана. Шуны укый да бетте. Төбенә төшеп тору юк. «Килде-китте хәбәрләр җибәрмәгез, башта мәгълүматны тикшерегез», – дип, ничә тапкыр әйттем инде. Моның өчен кешенең аңын тамырдан үзгәртергә кирәк шул.

Ә менә азык-төлек юнәлешендә хезмәт күрсәтүче Булатның иртәсе яңалыклар укудан башлана.

– Ил-көн вакыйгалары, дөнья күләмендәге хәлләр турында язучы мәгълүмат чыганакларыннан башка яши алмыйм, дисәм, дөрес булыр. Укуга, аны кемгәдер җибәрәсе, уртаклашасы килә. Әмма моның барысына да ошамаганын беләм, – ди ул. – Хәзер күпләр өчен блогерлар фикере бик мөһим. Монысын бик үк хупламыйм. Чөнки алар реклама, бартер, акча өчен теләсә нәрсә сөйләргә мөмкин. Аларны тыңлап ышанучылар һәм алданучылар да бар. Андый очраклар күп булды бит инде. Беркатлылык безнең кандадыр инде ул.

Ни өчен без теләсә нинди мәгълүматка ышанабыз? Ашлыкны кибәктән аерырга кем өйрәтер? Блогер Ринат Галиәхмәтовның фикерен сораштык.

– Якын кешеләрем арасында да андыйлар бар. Әйтик, берәр нинди мәгълүмат җибәрәләр, ди. «Тикшердегезме?» – дип сорыйм. «Ә аны ничек тикшерергә?» – диләр. Моннан тыш тагын берничә, кимендә 5–6 чыганактан, бу мәгълүматның дөреслеккә туры килү-килмәвен ачыкларга кирәк, – ди Ринат. – Бер җирдән генә мәгълүмат алып туктап калу дөрес түгел. Хәзер ялган хәбәрләр заманасы. Ясалма интеллект та – үсештә. Бәлки, ул фейк-фото, фейк-видео, фейк-хәбәрдер, уйлап табылгандыр? Әмма тикшереп утыручылар бик сирәк.

Көчле корал

Социаль челтәрләрне үз файдасына кулланучылар да бар, билгеле. Яңалыклар, кызык-мызыклар укып-карап утыру гына түгел инде бу, җәмәгать! Халык белән элемтә урнашты, бәлки әле ерагая барган араларны якынайту да. Мондый эшне түрәләр башкарса, аеруча күңелле.

Исегездә булса, Төбәк белән идарә итү үзәге (ЦУР) белгечләре халык белән социаль челтәрләрдә актив аралашкан, интернет челтәрен үзенең эшендә кулланган район башлыклары рейтингын төзегән иде. Иң яхшылар рәтенә Буа районы җитәкчесе дә керде. Аның өчен социаль челтәрләр һәм андагы мәгълүмат нәрсә икән?

– Социаль челтәрләр – диалог мәйданы һәм эшебездәге көчле корал. «Кышын подъезд ишеге боз белән каплана» дигән вак-төяк көндәлек мәсьәләләрне хәл итү өчен, мәсәлән. Вак-төяк булса да, ул бит кешеләрнең тормыш сыйфатына җитди йогынты ясый, – ди район җитәкчесе Ранис Камәртдинов. – Социаль челтәрләрдә без тиз арада белергә тиешле проблемаларга юлыгабыз. Әлбәттә, элеккечә халык белән очрашулар да уза. Әмма килеп чыккан хәл турында хәбәр итүнең оперативлыгы, аңа җавап бирү тизлеге ягыннан социаль челтәрләр әлегә барлык башка аралашу ысулларыннан өстен тора. Шул рәвешле мәсьәләне баштан ук хәл итеп була. Сирәк булса да, шәхси контент белән дә уртаклашам. Бу да – кеше белән аралашу, фикерләшү өчен нигез бит. Социаль челтәрләр «социаль» дигән исемен аклый: кешеләрне берләштерә һәм якынайта ул.

Сайлый бел!

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин да үзенең шәхси сәхифәсендә «мәгълүмати бирәнлек» (цифровое обжорство) мәсьәләсен күтәрде.

– Иң актуаль вакыйгалар һәм яңалыклар белән танышырга тырышучылар өчен ышанычсыз чыганаклар бәла булырга мөмкин. Бигрәк тә алар сыйфатлы, файдалы эчтәлектәгеләрен капларга тырышса. Яңалыклар тасмасында күргән мәгълүматны иләк аша уздырырга һәм сезгә файда китермәстәй фикер йөртүләрдән ераграк торырга өйрәнергә кирәк, – ди министр. – Минем киңәшем шул: кабул итә торган мәгълүматның сыйфатын беренче урынга куегыз. Ялзмаларның һәм авторларның абруена игътибар итегез.

Сайлау мөмкинлеге һәрвакыт бар. Берәү дә, моны кара, тегене укы, дип мәҗбүр итми. Социаль челтәрләрдә дуслык ике яклы булырга тиеш. Без бит аралашканда аралашасы килгән кешене сайлыйбыз. Шуңа күрә, социаль челтәрләрдә узган вакытыбыз файдалы һәм кызыклы булсын өчен, сыйфатлы эчтәлектәге контентка өстенлек бирегез. Таләпчән булыгыз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Мәгълүмати «диета»

Кирәк дип тоелган, әмма асылда мәгънәсез мәгълүматтан һәрвакыт хәбәрдар булу өчен сарыф ителгән вакытны исәпләп карасак, гаҗәпләнер идек. Шуңа күрә белгечләр әллә нигә бер булса да «диета» тотарга кирәклеген искәртә.

1 Мәгълүматны «монысы эш өчен», «монысы ял өчен» дип бүлеп карау дөрес булыр. Моның өчен хәтта социаль челтәрләрдә берничә төрле шәхси бит ясарга мөмкин.

2 Файда китерерлек мәгълүматка өстенлек бирегез. Ашаган ризыгыбыз организмга ничек тәэсир итә, кулланган мәгълүмат та кешенең физик һәм психик халәтенә шулай йогынты ясый.

3 Үз-үзегезгә сораулар бирегез. «Нинди максаттан?», «Бу миңа нәрсә бирәчәк?», «Бу дөреслеккә туры киләме?», «Бу бердәнбер чыганакмы?», «Әлеге мәгълүмат миңа тормышта кирәк булачакмы?»

4 Әллә нигә бер булса да үзегез өчен «мәгълүматсыз бер көн» оештырыгыз.

5 Сайт, социаль челтәрләр, телевидение… Мәгълүмат ташкынында югалып калмас өчен, кабул иteлә торган хәбәрне иләк аша уздыру кирәк. Хәзер гаджетларга махсус фильтр куеп була. Ул сезгә кирәкле булган мәгълүматны гына чыгарачак.

КУЕНЫ – ГӨЛБАКЧА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәхет өләшүче

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы, язучы хатыны, өч бала әнисе. Әле аларның берсенә аерым игътибар кирәк. Болар барысы да – Фидания Леронова турында.

– Татар хатын-кызы нинди була? – дисәләр, мин аны күрсәтер идем. Анда барлык сыйфатлар да тупланган. Сабыр да, шат күңелле дә ул. Беркайчан да күңелен төшерми. Бездән дә шуны таләп итә. Аның янында борын салындырып йөрүче юк. Мин әнине үземә гел үрнәк итеп куям. Әмма күпме генә тырышсам да, аның кебек булдырып булмый. Безнеке кебек әниле булу – меңләтә бәхет. Чөнки бар яктан килгән кеше ул, – дип сөйли кызы Айсылу. – Әниенең көчле хатын-кыз булуы энебез Бәхтиярне тәрбияләгәндә дә күренә. Кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырышты. Ә бит берәү булса, балам авыру, мин бәхетсез, дияр иде. Әмма әни өчебезне дә бертигез ярату һәм үзен бәхетле санады, бу хисләрен башкаларга да өләште. Моның өчен аңа зур рәхмәт. Әнигә сабырлык әбидән күчкән. Безне йокыдан уятканда да, ашарга чакырганда да җырлап кына дәшәр иде. Язучы хатыны буларак әтине илһамландыручы, аның иҗатын беренче мактаучы, беренче тәнкыйтьләүче дә ул. Ял итәргә дә вакыт табыла. Аллаһка шөкер, быел алар икәүләп хаҗ да кылды. Анысына да сөенәм. Кыскасы, һәркемгә минекедәй әни телим.

Хатын-кыз ихтирамга лаек

Танылган язучы, журналист Марат Әмирханов әнә шулай ди. Аның әтисе сугышта һәлак булган. Тормышның бар авырлыгы әнисе җилкәсенә төшкән. 90 яшенә җиткән Марат абый әле дә әнисен бик сагынып искә ала.

– Әнкәй мине һәм ике сеңлемне ялгызы үстерде. Ул һәрвакыт эштә иде. Безне әби-әбекәй тәрбияләде. Әбиебез бик саф күңелле, гадел, ышанучан иде. Безне дә үз үрнәгендә үстерде. Күп сөйләшмәскә, кешегә каршы сүз әйтмәскә өйрәтте. Аның тәрбиясе хәзерге көнгә бөтенләй туры килми. Хәзер калкып чыгарга, тырышырга, көрәшергә кирәк, ә безне башны иярга өйрәттеләр, – ди Марат абый. – Казанда пединститутта укыдым. Анда да күбрәк кызлар иде. Без берничә генә егет идек. Мәктәптә эшләгәндә дә, «Сөембикә» журналында да хатын-кызлар арасында булдым. Егерме елдан артык хатын-кыз проблемаларын өйрәндем, диярга була. Шуңа күрә, минем хатын-кызга карата хөрмәтем зур. Алар – моңа иң лаеклы зат. Хатын-кыз вәгъдә бирә икән, ул аны эшли. Әниләр дә шулай. Алар баласы өчен барысына да әзер.

Ачу сакламыйм

«ТНВ» журналисты, әлегә декрет ялында бәбиләр үстерүче Алсу Билданова ны язмыш бик сыный. Тудырган әнисе аны балалар йортында калдыра. Кечкенә кызны бер гаилә кызлыкка ала. Тик кызганыч, Алсуга 4 яшь чагында – әтисе, 10 яшьтә әнисе үлеп китә. Кызчык икенче мәртәбә әнисез кала.

– Әлфия әнием вафатыннан соң миңа бар җылысын аның апасы бирде. Без Разия апаны «әбием» дип үстек. Ул олыгайды инде. Әмма әле дә минем өчен яши. Икенче баламны алып кайткач, хәлемне белергә Казанга килде. Бер кәгазьгә минем һәм сеңлемнең телефон номерларын язып алган да Чирмешәннән юлга чыккан 86 яшьлек карчык. Миңа чит номердан берәү шалтыраткач, шаккаттым. «Әбиегез вокзалда, килеп алыгыз», – ди теге кеше. Әбине сеңлем табып алып кайтты. Шул вакыт эчендә ут йотып тордым. Аның өчен бик борчылдым. Кочаклашып елаштык, – дип сөйли Алсу.

Ятимлек ачысын татыган, хәзер инде үзе дә әни булган Алсу бу сүзнең мәгънәсен яхшы аңлый. Тормыш сынауларын узганда янәшәсендә булган хатын-кызларны якын итә ул.

– Кияүгә чыгып, яңа гаиләгә килеп кергәч, тагын бер мәртәбә әниле булдым. Әниемә озын гомер телим. Гел шулай аңлашып яшәсәк иде, – ди Алсу. – Мине тудырган әниемне дә эзләп таптым. Кайчандыр ятим иткәне өчен ачу сакламыйм. Хәтта мине калдыргаңы өчен рәхмәтлемен дә әле. Язмыш миңа бик яхшы әти-әни, бер дигән туганнар насыйп итте.

Сагынмаган кая ул!

Җырчы Азат Фазлыевның бәйрәм саен җаны телгәләнә хәзер. Кайтып котларга әнисе юк. Аны өзелеп сагынганын яшерми ул.

– Әни мине бик көтеп алган. Апам белән яшь аермам – 11 ел, абыем 6 яшькә өлкәнрәк. Бәби сөясе килеп, үзенең туган көненә – 32 яшенә алып кайткан ул мине. Кызганыч, рәхәт тормышны әниемә күрсәтә алмадык. Яман чир әнине арабыздан алып китте. Аннары әтисез дә калдык, – ди Азат. – Кирәк чакта усал, әмма бик тә кешелекле, туры сүзле кеше иде әни. Эшен җиренә җиткереп эшләде. Әле дә аның пешергән ризыкларын ашыйсы килеп өзгәләнәм. Әнием исән булсамы дим! Оныкларын күреп сөенер иде. Әни китте, кызыбыз Зифа туды. Аллаһы Тәгалә әниенең төсе итеп бирде аны. Нәкъ әнием инде. Тәскә-биткә дә – әни, холкы да аныкы. Ничә яшьтә булсаң да, әни кирәк. Йомшак кулларын, җылы кочагын бик сагынам. Һәр бала әниле үссен, әнисе исән булганнар кадерен белсә иде. Бәйрәмнәрдә генә түгел, гел сөендереп торыгыз. Бүләкләр дә кызганмагыз! Кадерләсәк иде әниләрне!

Әни үги түгел!

Апаста яшәүче Гөлчәчәк Вәлиеваның үз әнисе 43 яшендә вафат була. Әтиләре кабат өйләнеп, өч кызына яңа әни алып кайта.

– Әнине бик яратып яшибез. Аны «үги» дип әйтергә тел дә әйләнми. Ул гомере буе тегү текте. Безгә әниебезнең юклыгын сиздермәс өчен бик тырышты. Күңелендә бер дә начарлык булмады аның. Безне гел матур киендереп йөртте. Кичтән чалбар кисәк, иртәгесен ул күлмәккә дә әйләнә иде. Әни тегүче булганга, кытлык кичермәдек, ул безне бик рәхәт яшәтте. Без аңа гомеребез буена бурычлы. Ничек инде якын итмисең? Әни бит ул! – ди кызы Гөлчәчәк.

Бер әнинең ун шатлыгы

Балтач районының Кариле авылында гомер итүче 70 яшьлек Наилә Галиева – 10 балага гомер бүләк иткән кеше.

– Әниле кеше бәхетле, – ди Наилә апаның икенче баласы Рәмзия. – Безне дөрес тәрбияләде. Таләпчән булды, эшкә өйрәтте. Кая анда хәзерге балалар кебек каршы әйтү?! Барысына да житеште әни. Фермада сменалы эштә эшләде, әмма бөтенебезгә дә вакыт тапты. Без үскәндә керләрне кул белән юасы иде бит әле. Ә гаиләдә – 10 бала! Ашарга да пешерәсе. Дөрес, үсә бардык, кул арасына керә бардык. Тик әле дә әни сүзе – закон. Аны тыңлап яшибез. Әнигә бөтенебез дә якын. 10 бармакның кайсын тешләсәң дә, авырта, ди ул. Нәкъ шулай. Барыбызны бер төрле яратып яши. Төп йортка әнинең хәлен белергә гел барып торам. Бер генә теләк: әниле булып озак яшәсәк иде әле!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Һәр йортка тынычлык һәм мәхәббәт телим!»

Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры **Эльмира ЗАРИПОВА** Әниләр көне белән котлады.

«Бу бәйрәм гаилә кыйммәтләрен ныгыта, хатын-кызны ана буларак данлый. Республикада социаль ярдәм чараларына каралган һәр икенче сум балалы гаиләләргә юнәлтелә. Шул ук вакытта Татарстан гаиләләре федераль һәм республика социаль ярдәм чараларын да ала. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән кертелгән өстәмә социаль ярдәм чараларының максаты – гаиләләрнең иминлеген арттыру, аларның тормыш сыйфатын күтәрү, – диелә мөрәҗәгатьтә. – Кадерле хатын-кызлар, әниләр һәм әбиләр! Бәйрәм уңаеннан чын күңелдән котлаулар кабул итегез. Һәр көнегез елмаюлар, шатлык һәм бәхет белән тулсын. Һәр йортка тынычлык һәм мәхәббәт телим!»

СҮЗ КӨЧЕ

Кеше сүз эзли. Таяныр сүз, ышаныч биргән сүз, кыйблаңны билгеләргә ярдәм иткән сүз. Андый чакта аксакалга мөрәҗәгать итәсең. Без дә әдәбият, матбугат, милләт хәлләре турында сөйләшергә ил агасы, халык шагыйре Равил ФӘЙЗУЛЛИН янына килдек.

:: Равил абый, без нинди заманда яшибез?

– Төрле заманны кичтек. Алар арасында барысы да булды: сугыш чоры да, илне яңадан аякка бастыру еллары да, «коммунизм» төзү еллары да... 50–60 нчы еллар бигрәк хәтердә калган. Мохтаҗлыкка карамастан, халыкта рух көчле иде. Кызганыч, хәзерге чорда без ул рухны сизмибез. Шомлы, борчулы еллар кичерәбез.

:: Ил-көндәге бүгенге вазгыять иҗатта чагыламы?

– Ул әле әдәбият-сәнгатьтә кирәк дәрәҗәдә чагылмый, аңа мөмкинлек тә чикле. Чөнки берәүнең дә куәләтә нахак бәла аласы килми. Без – нахак сүз өчен күп газап чиккән халык.

> Бер чабылганнан соң курпы үсә. Ул инде печән түгел. Башыннан зур афәтләр үткәргән халык әнә шул курпы хәлендә.

:: Ә бит «Татар әдәбияты заман белән бергә атламый, йомшак, тешсез», – диючеләр дә бар...

– Безнең әдәбиятның үткәне, бигрәк тә бүгенгесе турында күбрәк әдәбиятны белмәгән кешеләр сөйли. Ул аны укымаган да була. Татар әдәбияты тарихын белгән кеше андый сүзне әйтмәс. Ни өчен? Чөнки безнең ныклы, тарихи нигезебез бар, тик кызганыч, аны кирәк дәрәҗәдә белмибез. Ә бит уйласаң, безнең әдәбиятта һәр гасыр саен берничә зур галимне, фикер иясен, язучы-шагыйрьне атап була. Мондый тарихи байлык сирәк әдәбиятта гына бар. Әйтик, рус әдәбиятында да исемнәр, конкрет авторлар аталган әсәрләр XVIII гасырдан гына башлана.

Мин кайчакта әдәбиятны Сабан туендагы хәлләр белән чагыштырам. Әнә мәйданда көрәш бара. Көрәшчеләр, көрәшкәндә кызышып китеп, аяк чалырга, хәрәмләшергә дә мөмкиннәр, үзләре аны сизмәүләре дә бар. Ә карап торучылар сизә. Безнең әдәбият – зур әдәбият булса да, кызганыч, рухи мәйдан уртасында түгел. Теле киселгән. Карап торган кеше күбрәк күрә, аның эчке хәсрәте бар, ул күбрәк уйлана һәм объективлыкка якыная. Мәйдан уртасында булмагач, бездә күпмедер кимсенү дә бар. Әмма зур әдәбиятлы халык булуыбызны танымый мөмкин түгел. Хәзерге хәл ничек кенә авыр булмасын, әдәбиятта әлегә көчләр бар. Ә менә алга таба ниләр булыр?.. Иң аянычы – безнең мәгариф системабыз юк. Моны аерымлап, басым ясап әйтергә кирәк.

:: Туксанынчы еллар белән чагыштырганда, соңгы вакытта язучыларның иҗат итү шартларын кайгырту ныграк сизелә. Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе бу җәһәттән әдәби конкурслар игълан итте, әдәби грантлар бирә башлады һәм башка саваплы гамәлләр эшләнә. Бу кайгыртучанлык яхшыдыр, бәлки аның тискәре йогынтысы да бардыр...

– Соравыгызда җавабы да бирелгән. Бу – аптырагачнан эшләнгән эшләр инде. Чыннан да, язу белән шөгыльләнүчеләрнең, язучы булсынмы ул, журналистмы – матди хәлләре әйбәт түгел. Яшерен-батырын түгел, түләү – каләмхак юк дәрәҗәсендә. Булдыра алган хәтле ярдәм итәргә телиләр. Сер түгел, хәзер әдәбиятны аз кеше укый. Җитәкчеләр яшь буынны әдәбиятка юнәлтмәкче, кызыксындырмакчы булалар. Бу очракта рәхмәтле булырга тиешбез.

:: Заказга язылган әсәрнең файдасы булырмы икән?..

– Менә монысы уйландыра. Анда катгый шартлар куела, әйтик, автор әсәрен фәлән вакытка өлгертергә тиеш. Тарихи әсәр язарга алынган кеше бу вакытка сыеша алмаса? Минемчә, объективрак тарихи әсәр язу өчен, берничә буын тарихчы булу кирәктер. Аңа бер генә гомер җитмәскә дә мөмкин. Ә грант шартларына буйсынганда әсәрне ашыгып эшләргә туры килә.

:: Бүген чыгарган китапны иртәгә укучы булырмы?

– Кешегә фикер кирәк. Адәм баласының аптыраган чагы була, эзләнгән чагы. Шушы халәтеннән чыгарга фикер ярдәм итә ала, ул нинди телдә әйтелсә дә, кирәк кеше аны эзләп табачак. Иң башта бит фикерең булу кирәк. «Нинди заманда яшибез?» – дип сорадыгыз бит әле. Шушы заманны ничек яхшыртырга? Без аны киләчәккә яңа буыннарга нинди килеш тапшырабыз? Без туктаусыз җавап эзләүдә. Шуңа күрә чын язучы әсәрләре укылыр, дим әле мин.

:: Бу сорау матбугатка да кагыла. Газета-журналларның киләчәген ничек фаразлыйсыз?

– Матбугатның хәле мактанырлык түгел. Бу очракта кәгазь басма матбугат турында сүз бара. Тырышып, бик нык оештырып йөрүләр нәтиҗәсендә генә тиражларны беркадәр саклый алабыз. Башка төбәкләр белән чагыштырганда бездә хәлләр әлегә яхшырак. Әмма җитди проблемалар да баштан ашкан. Бу очракта иң әүвәл кадрлар кытлыгы. Журналистикага да, әдәбиятка да ир-егетләр килми диярлек. Безнең заманда да әдәбиятка килү җиңел түгел иде. Ләкин анда сәбәпләр башка: бастырырга мәйдан юк иде. Хәзер мәйдан да бар, ләкин эшкә тиешле бәя – түләү юк. Шуңа күрә әдәбиятка хәзер йә артык бөекләр, йә фанатиклар гына килә.



Равил Фәйзуллин – әдәбиятка яшьли килеп кергән шәхес. Аның беренче шигырьләре узган гасырның 50 нче еллар ахырында матбугатта күренә башлый. Студент елларында ук Казанда ике шигъри китап чыгаруга ирешә. 22 яшендә Язучылар берлегенә кабул ителә һәм СССРда Язучылар берлегенең иң яшь әгъзасы була. Ул – алтмышынчы елларда әдәбиятка шаулап килгән яшьләрнең берсе. Кыю иҗаты, гражданлык активлыгы популярлыгы, таланты аны шул чор шагыйрьләренең лидеры дәрәҗәсенә күтәрә. «Фәйзуллиннар буыны» дигән төшенчә әнә шул елларда ук барлыкка килә.

Безнең заман белән чагыштырганда бүгенге яшьләргә авыррак та әле. Аның кредиты бар, ул берничә җирдә эшләргә мәҗбүр. Иң аянычы – аның бүгенге көн тотрыклылыгына ышанычы юк. Ә безнең заманда ышаныч зур иде. Мәктәптә бик яхшы укыганнарның вузга керәчәгенә шиге булмады. Ә инде диплом алгач, эш белән тәэмин итәләр иде. Ул эш белән тормышны алып барып булды. Традицияләрне буыннарның табигый алмашы булганда гына саклап була. Менә шул бозылса, нигез какшый. Бу инде дәрәҗәгә дә, сыйфатка да суга.

> Мактанып әйтерлек сүз түгел түгелен, әйтмичә дә булмый: моңарчы матбугатны нигездә өлкән һәм урта буын тартып барды.

:: Халыкның матбугаттагы сүзгә ышануы ни дәрәҗәдә?

– Матбугатта басылган сүз халыкка тәэсир итми калмый. Элек газетага мактап язсалар да, тәнкыйть мәкаләсе чыкса да, нәтиҗәсе бар иде. Тәхеткә акча менгәч, сүзнең көче кимеде. Бу җәһәттән теләсәң дә, оптимист булу кыен.

Матбугат халыкны ияртергә тиеш. Киресенчә, хәзер ул халыкка иярә. Кем өйләнгән, кем аерылган һәм башка көнкүреш ваклыклары – бу матбугат эше түгел инде. Элек мәгълүмат аз булса да, без аны дөнья масштабына үлчәп кабул итә идек. Хәзер мәгълүмат бик күп, кыйбласы гына юк.

:: Матбугатның һәм китапның интернетка күчү ихтималы зурмы?

– Кәгазь китап һәм матбугат безнең гомергә җитте. Алга таба ничек булыр, фаразлау кыен. Яшьләр бик акыллы бит хәзер. Акча эшләүнең әллә нинди юлларын уйлап табалар һәм булдыралар да. Миңа ошамый дип кенә тормыштан интернетны аерып атып булмый да, ярамый да. Әмма мин кәгазь китап һәм кыйбланы тотарга тырышкан дәүләт басмалары яклы.

:: Сез – әдәбиятта да, тормышта да яңалык алып килгән кеше. Икесен дә кабул итүче дә, итмәүче дә булгандыр. Тормышка яңалык дигәндә, мин Фәйзуллин йөзүләрен күз уңында тотам. Быел ул 45 нче тапкыр узды, илленчесенә әзерлек ничек бара? Тормыш рәвешегез турында берничә сүз.

– Язучылар белән беренче йөзүне оештырганда миңа 35 яшь иде. Без төрле җирләрдә йөздек. Иделдә, Чулманда, Казансуда, бүтән урыннарда. Аның хикмәте менә нәрсәдә. Без сулыклары күп булган җирдә яшибез. Бер караганда су буйларында пляжлар да шактый, халык йөзүдән битәр яр кырыенда ятып торуны кулай күрә. Су спорты төрләре өчен Йөзү сарае да бар, анда исә күбрәк спортчылар ярыша. Су буенда яшибез, әмма су спорты бездә бик таралмаган. Авылларда йөзүнең нәрсә икәнен дә белмиләр. Аның сәбәбен аңлыйм да кебек. Авыл кешесенең башын күтәрергә дә вакыты юк, ул гел эштә. Аңа утыны да, печәне дә кирәк, ул гомер буе эшли. Мин йөзүләрне яшьләргә йөзү культурасы кермәсме дип оештырдым. Бу бит – табигатькә якынаю да. Тәрбияви әһәмияте дә бар.

> «Су өстендә куллар – таянычым!
> Җир-күк өчен алар – кул гына...
> Кош күк оча кеше! Оча!..
> Түбәнендә – һава урынына су гына!
> Аермалар бары шул гына...
> Кемнәр әйтә, Күктә оча, диеп,
> Кеше фәкать суда оча ала!»

:: Язучының кумиры буламы?
– Кумир ул яшь чакта кирәктер. Алар кебек буласым килгән язучыларым бар иде. Мин күп укыдым. Чит ил әдәбиятын да, үзебезнең язучыларны да. Чыңгыз Айтматов, Кайсын Кулиевлар кебек буласы килә дип тә укылды. Үз вакытында Джек Лондонның «Мартин Иден» дигән әсәре бик тәэсир итте.

Ә кумир дигәндә, иң төп кумир халык инде ул. Моңа инану өчен, кулыңа Нәкый Исәнбәтнең халык җәүһәрләрен туплаган мәкальләр 3 томлыгын алу җитә.

:: Исән чакта музее булдырылган язучылар бик сирәк...
– Туган җирем Балык Бистәсе районы Балтач авылында музей ачу урта мәктәпне саклап калу нияте белән дә эшләнде (әлеге мәктәп инде 20 ел Равил Фәйзуллин исемен йөртә. – **Ред.**). Иң сөендергәне: «үле» музей түгел. Гөрләп эшли, кунаклар кабул итә, бу исә авылга да игътибарны арттыра.

:: Бүген нинди мәшәкать, уй-планнар белән яшисез?
– Юбилей дигәннәре (быел бит миңа 80 яшь тулды) шактый уйга тарытты. Күпләр юбилей кичәсен үткәрүне тели. Ә үземнең юкса кешеләргә дә, үземә дә мәшәкатьләр тудырасым килми иде. Шулай да, берәр иҗат кичәсе (котлау кичәсе түгел, иҗат кичәсе) үткәрергә булыр, ахрысы... Әлбәттә, язучының төп эше, мактанычы китап инде аның.

:: Иң зур теләгегез нинди?
– Исәнлек телим. Ул – Ходай биргән иң зур бүләк. Шәхси саулык – бер хәл, милләткә саулык сорыйм. Киләчәк буын бездән яхшырак булсын иде. Аның аңа хакы бар. Без – авыр язмышлы халык. Мин аның бер күзәнәге буларак, милләтебез яшәсен иде, дип телим. Һәр кеше үзеннән кечкенә генә өлеш кертсә дә, милләт яшәячәк. Битараф булса яисә каршы сукалап, киресен эшләсә, юкка чыгу ихтималы да арта. Әмма милләтнең киләчәгенә ышаныч белән карыйм мин.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Нюанслар иле

Равил ФӘЙЗУЛЛИНның заманында шау-шу куптарган, шигъриятькә яңалык алып килгән кыска шигырьләре, ниһаять, шушы арада тулырак вариантта дөнья күрәчәк. «Нюанслар иле» китабына кыска фәлсәфи-лирик шигырьләре тупланган. Татар әдәбияты классиклары сафындагы әдипнең меңләгән шигъри әсәрләре тулаем бер җыентыкка кереп бетә алмагандыр, әмма сайлап алынганнары да шагыйрь шәхесенең зурлыгын раслый. Бу дүртьюллыклар әнә шул китаптан.

Бер генә!
Туган җирең чүл булса да,
күңелдә ул – гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

Тел-тел, дибез...
Реанимациядән
чыгармы берәр рәт?
Кисек юан тамыр –
милли мәгърифәт!

Искәртү
Дуслык җырым бүлеп чукынма!
Тарихи ярамда тукынма!
Каһәр ташы булып татарның
Бугазыңа кереп ятармын!

***

Арысландай басып, үләндә йөр!
Һәм лачындай оча ал җилпенеп!
Нужаларны күтәр сулар кебек!
Хәсрәтләрне йота ал җир кебек!

***

Кызыкмыймын биек түрәлеккә.
Исем китми алтын кәшелгә.
Гомерем буе табынып килдем
Саулык белән Яхшы исемгә.

Кредо
Зур кеше шул: кем үзенә
Һәм Вакытына үзе Алла.
Бәхетле шул: кем иреген
Һәрнәрсәдә тоя ала.

Җиңел түгел
Нахактанмы, пычактанмы –
җиңел түгел яра.
Гөлнең дә, багананың да
күләгәсе кала.

Бу заманда
Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
даның, януың кирәк.
Януыңны халыкларның
күмәк тануы кирәк.

Ил өчен
Инешләрнең башы чишмә булыр.
Яхшылыкның асылы – турылык.
Яшәү – бәхет: илең – синең өчен,
син ил өчен булсаң горурлык.

Яшәп кара...
Яшәп кара бер маяксыз!
Йөз җыерып хаклыктан!
Фикерең илтсәң сатлыкка –
кол булырсың ваклыкка.

Яме!
Нык тораммы, чайкаламмы,
Күккә ашаммы, аваммы?.. –
Хурлыгымны оныт та бул
Зурлыгымның дәвамы!

Картлар сүзе
Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

***

А. исәләгенә

Арысланнар йөрми көтү белән.
Йолдызлар да
бер куч кебек
күренә генә.

Елмаюың...

М.-гә

Гомер буе серле елмайдың син...
Булдым, димим моңа гел риза.
Кемдер, бәлки, аңлый алыр булган
Минем Мона Лизам!

***

Зур кайгылар баса кечерәген,
олы ялкын капләый күмерне.
Аңлар җанга һич төзәлмәс яра –
зая үткән көне гомернең.

***

Намус – җаның сакчысы.
Еллар – гомер баскычы.
Кылыч – күкрәк ачкычы.
Шигырь – йөрәк ачкычы.

***

«Улым!» – диючеләр кими, кими...
Иртә китте бабай-әтиләр...
Тик бер өмет: лаек булып, бәлки,
Ил «улым» дип дәшәр ятимгә...

***

Дуслар тыныч: кирәктә дә дәшми, –
карап тора, аңлап тора...
...Ятлар сизгер, сак: колак шомартып,
ялгышыңны аулап тора.

Шаяру
Гашыйк Гарип... Гашыйк Гомәр...
Гашыйклары бары – данлы ил!
Шул гашыйклар арасына
Сыймас дисез мәллә бер Равил!..

***

Сәясәттән ераклашкан саен,
табигатькә ныграк елышам.
...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
елан үтеп киткән юл аша.

Бер...
Башың биш булса да,
аулыгың бер.
Нәфсең ун булса да,
саулыгың бер.

***

Өстәлемдә – хәләл икмәгем.
Күңелемдә – иреге мне тойган горурлык.
Кешеләрнең күңелендә –
азмы-күпме җыйган яхшы атым.

***

Әгәр Ватаның җуелса –
гадел үч һәм коч телим.
Әгәр сөйгәнең җуелса –
Кавыштырыр төш телим.

Бер ветеран сүзе
Асты – өскә, өсте аска
Әйләнде дөнья безгә!
Колмак бата, таш йөзә...
Йөрәк тузды, баш түзә.

***

Гел «мин!», «мин!» дип сөйләнгән җан
беркөн үзен югалтыр...

Бер-беребезгә «без!» дип әйтсәк,
җирдә бердәмлек артыр!

Кояш астында яшим дисәң...
Максатың булсын да, хөрлегең булсын!
Сөйгәнең булсын да, ирлегең булсын!
...Тәпи басарга һәм күмелергә
тәгаенләнгән җирлегең булсын!

Акмулланы укыгач
«Йорты Болгар улса улсын –
Йортны болгар улмасын!
Исеме татар булса булсын,
җанны сатар булмасын!

***

Көнләшүдән бигрәк соклан, туган!
Акны барыбер «ак ул!» диярләр.
Хак сүзне гел «бал» димәсәләр дә,
хәсетлекне «агу» диярләр!

***

Һай бу гомер!.. Көтеп-көтеп
туган кадәр дә юк!
Яшәр дәвер – таңда төшкән
томан кадәр дә юк!

***

Җан тынлыгын бозып дау булдым.
Үзәннәрдә торып тау булдым.
...Килде көн: Син яннан үткәндә –
иелеп калыр өчен тал булдым!

Вакытның хәтере шәп аның...
Тиз чигәбез телдән, тарихтан...
Чүккәнбез Бүгеннең тезенә...
Вакытның хәтере шәп аның! –
Бик тиз онытырлар безне дә...

***

Кош бит мин! Шуңа егылмыйм, –
имгәнми генә авам...
Кеше шул мин: күккә генә
сыймаслык йөрәк ярам.

***

Хәләл дими, хәрәм дими,
җыя гел, «ашым!» диеп.
...Дөнья да гадел усал –
костыра, башын иеп!

***

Күтәрер әләмең булмаса,
ышанар адәмең булмаса, –
күңелендәге ил турында
сузып җибәр җыр, булмаса!

***

Кешеләрне зурлап сөйләү –
хикмәт булыр.
Җансызларның иң җанлысы –
Икмәк булыр.

Безнең көннәргә штрихлар
Урылмый калдылар игеннәр.
Кыраулар өшетте мул кырны.
...Базарның чатында угрылар
гармунын алдылар сукырның.

Бу көн...
Еланнар терелгән көн...
Сират күперен чыкмый гына
акчалыларга җәннәткә
юллама бирелгән көн.

***

Уйладым: минем гомерем
Ике-икең – биштән тора...
«Тудым-үлдем» дигән фигыль
Сиксән килештән тора!

***

Таркау булсак, берләшмәсәк,
инкыйраз ул булачак...
Нәрсәгә чит телләр белү,
туган телне югалтсак?

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

4–14 декабрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана.
30 ноябрьдә уйнатылачак бүләк –
АЛЬБИНА ФАЗЛЫЕВАдан ЧАЛМА

Бу атна җиңүчесе – Балтач районыннан Әхмәдиев Фәнис.
Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Әз-мәз мәзәк

– Хатын-кызлар теленә миңа бирәр нәрсә әйт әле.
– 3 ел элек бер кызга лайк куйган идеңме, менә шул әйтсен, аңладыңмы!

***

«Яңалыклар булмау – үзе үк яхшы яңалык», – ди минем дустым. Болай начар кеше түгел ул үзе, әмма никтер журфакка укырга керә алмады.

***

– Йөклелекнең беренче билгесе нинди?
– Үз алдыңа шушы сорауны кую.

***

– Беренче мәхәббәт ул һәрвакыт истә кала.
– Әйе. Туй белән тәмамланмаса.



Беләсең килсә...

1 Бу җанвар бик күп атамалы булуы белән Гиннесс рекордлар китабына кергән:
а) коала;
б) тау кәҗәсе;
в) пума.

2 Дирижер Ильяс Камалов кайсы театрда эшли?
а) Камал театры;
б) Тинчурин театры;
в) Әлмәт театры.

3 Бу шәһәрдә 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты уеннары узмады:
а) Уфа;
б) Самара;
в) Саранск.

4 Мондегрин нәрсә ул?
а) җырдагы сүзләрне ялгыш ишетү;
б) мандарин белән грейпфрут гибриды;
в) урманнан исә торган җылы җил.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. а); 4. а).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Сабантуй, өмә, Искәндәр, дус, әби, ом, Ка, мол, яман, Татарстан, ВИА, анда, Саф, аксым, мә, ушу, Уфа, ләм, Равия, яну, оя, Нурлат, Явкин, ОТР.

Вертикаль: спидометр, мул, сумо, Сәфәров, бакс, Литва, Амаяк, АиФ, нон, ара, ИНН, яу, ятак, ро, йөрәк, Мансур, ялт, Баландыш, анар, Нәби, Амур, ут.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 357

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+